*Марсель Әхмәтҗан*

# Турай, Миякә арасы – бар да меңнәр баласы

Казан – 2010

ББК 63.3(2Рос=Тат)
А 93

***Әхмәтҗанов М.И.***
**Турай, Миякә арасы – бар да меңнәр баласы.** – Казан, 2010. – 56 б.

© Әхмәтҗанов М.И., 2010

# КЕРЕШ СҮЗ

Нугай Урдасын төзүче татарларның шәҗәрә язмалары безнең тарафтан төзелеп, эшкәртелеп, тарихи искәрмәләр язылып безнең тарафтан 2002 һәм 2009 елларда басылган «Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы» исеме белән ике китап рәвешендә дөнья күрделәр һәм халык арасында танылып, таралдылар.

Әлеге теманың хәзерге көндә өченче китап рәвешендә дәвамы язылып ята. Ләкин кызганычка каршы татар китабын бастыру һәм тарату юлына куелган «кризис» дигән имән күсәкләр ул китабыбызны бастырып чыгаруга бик аз өмет калдыра.

Шунлыктан әлеге китапның иң кыйммәтле сәхифәләреннән берничәсен аерым брошюра рәвешендә булса да чыгарып, бастырып калдыруны кирәк дип таптык.

Җыентыкның беренче өлешенә Дим елгасы буеның югарыгы агымында, төгәлрәге Миякә төбәгендәге татарларның Газиз Вафин тарафыннан 1960–1970 еллар арасында төзелгән тексты, икенче өлешендә Канзафәр бинең өченче улы Шәйех Дәрвиш (шулай ук Шәйех Дирбеш дип тә мәгълүм), нәселенә караган өч шәҗәрә тексты кертелде.

*Марсель Әхмәтҗанов*
филология фәннәре докторы
30 январь, 2010 ел

# МИЯКӘ ТӨБӘГЕННӘН МЕҢНӘР КАБИЛӘСЕ ШӘҖӘРӘСЕ

XVII гасырның 30–40 елларында Нугай Урдасы дәүләтенең биләмәләре хәзерге Башкортостан Республикасының Миякә төбәге аша агып үтә торган Дим елгасы һәм аның кушылдыгы булган Уязы елгалары буйларындагы Шатмантамак, Олы Каркәле, Качаган, Баязит, Җилдәр, Дим Айыты, Дүсән, Янбак, Җылыбылак, Өйәзебаш, Сарманай, Таллыбылак, Миякә, Эстәрлебаш (Стәрле елгасы буенда), Благовар төбәгендәге Сарайлы авылы, Асылы күл кебек күл, Дим елгасының көнбатышында Бөгелмә тирәләренә кадәр, Җайык (Урал) елгасының көнбатыш өлеше җирләре булып, меңнәр кабиләсенә караганлыгы аңлашыла.

Шәҗәрә Каркәлетамак авылыннан Вафин Газиз Мөхәммәдвафа улы тарафыннан 1963–1970 елларда төзелеп, Казанга Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына 1971 елның 5 декабрендә җибәрелгән. Әлеге документ тексты Дим елгасының башы һәм урта агымнарының Нугай Урдасына нинди мөнәсәбәттә яшәгәнлеген һәм андагы татарларның ничек тар-мар китерелүен аңларга ярдәм итә.

Бу меңнәр кабиләсе шәҗәрәсенең безнең кулда Зөя, Ашыт, Мишә, Казанка буйларыннан алып, Агыйдел, Чулман, Дим, Ык буйларына кадәр таралышын күрсәтә ала торган дистәдән артык эреле-ваклы текстлары фонында Вафин Газиз төзегән тексты бик урынлы күренә. Шәҗәрәдә төп бабаларның берсе булган Канзәфәр би Гәрәй би улының нәселе легендалары язылып берничә нәсел җәдвәлендә чагылыш таба. Ләкин моңа хәтле безгә мәгълүм текстларда Канзәфәр һәм нәсел чылбыры янында легендалары булмау, аның төп яшәгән урынын, билгән җирләрен төртеп күрсәтергә кулны тота иде, хәзер инде бар да ачык. Канзәфәр һәм аның балаларының төп яшәгән урыны – Кырык Өйле исемле авылда, Асылыкүл тирәсендә булган.

«Кырык Өйле» атамасына якын булган беренче хәбәр Татарстанның Әлки районы Яңа Ургагар авылында табылган «Исак шәҗәрәсе»ндә сакланган. Исак нәселе Кама арьягына хәзерге Нижний Новгород өлкәсе Курмыш төбәге Петраксе авылыннан күчеп утырган. Шәҗәрәдә төп баба Исак, аннан туган Дусак, аннан туган Янгыйнай, аннан туган Кыркыйл һ.б. дәвам итә.

Кыркыйл → Кырык + ил ысулы белән ясалган исем, этноним.

Кырык өйлеләр турында мәгълүмат тагын Учалы төбәге Ахун авылы шәҗәрә китабында берничә урында бар. Ахун авылын нигезләгән Ахун Даушев белән Саратов, Темников, Царицын якларыннан килгән нәселләр авылның шәҗәрә китабында кырык өйлеләр төркеменә керәләр[1]. Ахун авылы нәселләре арасында да Канзәфәр (Казанфара) нәсел шәҗәрәсе китерелә. Алар анда Нугай Урдасының меңнәр кабиләсенә нисбәтләнеп карала. Ахун авылы шәҗәрәләре китабына № 30 сан белән кергән «Урдач би ыруы» шәҗәрәсендә Канзәфәр (Казанфара) би Кәрәй би улы итеп күрсәтелә. Бу очракта текст Миякә төбәге шәҗәрәсе белән туры килә яза. Тик соңгысында Канзәфәр би Гәрәй би углы диеп күрсәтелә. Ә Канзәфәрнең улы Ахун шәҗәрә китабында «Вәйтәк би» диеп язылган, анда аның тагын Дистан, Шәйех Дирбеш, Шәйех Хәсән, Әбүшахма исемле уллары телгә алынмый.

Миякә ягында Канзәфәр бинең туганнары, аның балалары хакындагы борынгы хәбәрләр Вафин Газиз шәҗәрә төзегән 1963–1970 елларда инде нык кына онытылып калганнар диеп фикер итәргә кала.

Канзәфәр ыруының биләгән җирләре Дим елгасының югары башы аккан Миякә төбәгенә хәтле җиткән. Канзәфәрнең дүрт улы – Абүшахмә, Шәйех Дирбеш, Дистан, Шәйех Хәсән исемнәре тотрыклы рәвештә берничә күчермәләрдә күрсәтеләләр. Миякә шәжәрә тексты Канзәфәрнең дә яшәгән дәверен шактый анык тәгаенләргә ярдәм итә. Халык риваятьләреннән күренгәнчә, Дим буенда калган

---

[1] Әхмәтҗанов М.И., Солтанов В. Ахун авылының нәсел тарихы. – Казан: Гуманитариа, 2004. – 8 б.

татарлар бер дә үз теләкләре белән коллык камыты кияргә Мәскәүгә бармаганнар. Бу коммунистлар партиясе тарафыннан Мәскәү князьлеге тирәсендә яшәгән халыкларны – мордваларны, украиннарны, полякларны, марижарны, чуашларны, башкирицларны, Төньяк Кавказ, Урта Азия, Себер халыкларын үз теләкләре белән Мәскәүгә кушылу турындагы ялган легендаларның берсенең тагын бер кат сабын куыгы икәнен күрсәтә.

Канзәфәр би үз тарафдарлары белән басып алучыларга каршы озак көрәш алып барып һәлак булган. Аның һәм балаларының биләгән җирләрен тартып алып, килгән килмешәкләргә бу җирләрне басып алуга булышкан өчен өләшкәннәр. Яулап алучылар шулкадәр монафикь адәмнәр булганнар ки, аларга Канзәфәр нәселеннән тартып алынган җирләрне өләшкәндә, документлар белән хәтта иске хуҗаларының фамилияләрен дә беркеткәннәр. Мәсәлән, Дистан җирләренә бу фамилиягә мөнәсәбәте булмаган кешеләргә Дистанов фамилиясен дә кушып биргәннәр.

Вафин Газизнең бер зур гына кимчелеге дә бар, ул монда бер дә Нугай Урдасы җирләре булуы турында дәшми, төбәктә беренчел булып гел башкортлар гына булган кебек фикер йөртә. Шул ук вакытта 12 татар авылының тар-мар китерелгән ятимнәрне тәрбиягә алырга кайдан килүләре турында да сүз юк. Сирәк очракта типтәрләр сословиесендә йөрүчеләр искә алына. Шәҗәрә текстының теле татар теленең типтәр үзенчәлеге дип кенә санарлык саф татар теле булуы бәхәссез. Шәҗәрәне төзүче Уфадагы Тел, әдәбият институтында да булган, аларның заказын үтәргә инструкция алганлыгын үзе язып калдырган. Ул Казанга җибәрелгән текстның бер нөсхәсен Уфага җибәрүен дә яза. Без аның инвалид булган хәлдә бик зур ватанпәрвәрлек хезмәте калдыруын таныйбыз, аның хезмәтендәге вак-төяк кимчелекләрне генә төзәтерлек мәгълүматларыбыз бар. Шәҗәрә тексты кириллицада, бер табак кәгазьнең ике ягына тутырып язылган. Обьективлыкны күздә тотып Вафин Газиз төзегән шәҗәрәнең башта комментарий, тарихи легенда өлешен тулысынча укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.

Кульязма кәгазе инде кырык еллар чамасы элек язылганлыктан, шактый кыршылган, саргайган урыннары, карасы уңган җирләре бар. Язучының да үз специфик кулы күренә, ләкин тулаем алганда укырлык һәм аның текстын күчереп яңарту вакыты күптән җиткән. Минем кулыма бу шәҗәрә әле 2009 елның февраль-март айларында гына керде һәм мин аны өйрәнүне беренче мөмкинчелек табу белән үк башладым.

*Марсель Әхмәтҗанов*
филология фәннәре докторы

## КАНЗӘФӘР БИ ШӘҖӘРӘСЕНЕҢ ТАРИХИ КЫЙММӘТЕ ТУРЫНДА

Канзәфәр би нәсел шәҗәрәсе нигездә кеше исемнәреннән – антропонимнардан гына торса да, анда халыкның сөйләм теленең үзенчәлекләрен графофонетик алымнардан чыгып билгеләп була.

Шәҗәрәдә исемнәре теркәлгән кешеләр хәзерге Башкириянең Миякә, Бишбүләк районнары аркылы агып үткән. Дим елгасының Уязы, Миякә исемле кушылдыклары буйларында яшиләр, йорт тоталар.

Бу җирләр 17 гасырның беренче яртысына кадәр Нугай Урдасы дәүләтенең һәм халкының җирләре, милке булганнар. Бу очракта, шәҗәрәдәге кеше исемнәрендә Нугай Урдасы татарларының тел үзенчәлекләре теркәлеп калганлыгы бәхәс уятмый. Уфа галимнәренең шәҗәрәләр ниндидер ата-анасыз «төрки» телдә язылганнар дигән «ачышларын» – анализлана торган шәҗәрә тексты 100% сөртеп ташлый. Уфа сәясәтчеләренең «татарлар башкортларны ассимиляцияләгән», – дигән тезис та бер чүбектән гыйбарәт икәнлеге ачыла төшә. Нугай Урдасы дәүләте татарларының теле әлегә хәтле, иң кимендә XX гасырның

60–70 елларына хәтле үз табигый үзенчәлекләре белән яшәп килгәнлегенә дәлил.

Анның иң ныклы, тотрыклы үзенчәлеге «ж» фонемасының төбәк сөйләшендә актив кулланылышта булуында. Шәҗәрә текстында без, әдәби татар теле нормасы буенча «й», «җ» фонемалары кулланылган урында тотрыклы «ж» кулланылуда күрәбез. Мәсәлән, бу үзенчәлекнең чагылышы текст телендә түбәндәгечә күренә:

| **Язылыш** | **Әдәби норма** |
|---|---|
| Жыл(ы)былак (гидроним) - | Җылы Болак |
| Жилдәр (топ оним) - | Җилдәр |
| Хужиахмад (антр.) - | Хуҗа-Әхмәд |
| Хажгали (антр.) – | Хаҗи Гали |
| Габделжалил (антр.) - | Габделҗәлил |
| Мажид (антропоним) - | Мәҗит |
| Жалил (антр.) - | Җәлил |
| Габделмажит (антр.) - | Габдел-Мәҗит |
| Хабибжан (антр.) - | Хәбибҗан |
| Гарифжан (антр.) - | Гарифҗан |
| Жагфар (антр.) - | Җәгъфәр |
| Габделжабар (антр.) - | Габделҗаббар |
| Шакирян (антр.) - | Шакирҗан |
| Хасанжан (антр.) - | Хәсәнҗан |
| Амиржан (антр.) - | Әмирҗан |
| Жигангир (антр.) - | Җиһангир |
| Сабирян (антр.) | Сабирҗан |
| Газизян (антр.) - | Газизҗан |
| Минһажетдин (антр.) - | Минһаҗетдин |
| Жалялетдин (антр.) - | Җәлалетдин һ.б. |

Икенче бер фонетик үзенчәлек «ж» тартыгының акрынлап «й» графофонемасы белән кысрыклана баруында күзәтелә.

Хәлбуки, бүгенге нугай халкы телендә «ж» фонемасы тотрыклы саклана. Аларда «җ» авазы юк, лимәк Димнең югарыгы башларында яшәгән Нугай Урдасы татарлары телендә «җ» тартыгы булмаган.

«Ж» лаштыру күренеше бүгенге казак халкының телендә дә норма буларак яши, анда «җ»лаштыру очраклары күзәтелми. Казагыстанның Җайык елгасы буйларында урта гасырларда хуҗа булып торган Нугай Урдасының халкы теле нормалары казак теле формалашуга үзеннән җитди өлеш кертеп калдырган.

Татар теленең көнбатыш диалекты сөйләшләре өчен «җ» фонемасу куллану хас түгел. Шунлыктан ул сөйләшләрдә «җ» авазы күпчелек очракта «й» һәм сирәгрәк очракта «з» белән алышына[2]. Ихтимал, Канзәфәр би шәҗәрәсендәге антропонимнарда «ж» тартыгы әкрендәп кыска «й(а)» га алышына бару процессы, бу якларда җирле халыкка көнбатыш татарларының көчеп килгәч беркадәр тел йогынтысы булганлыгы күрсәткечедер.

Антропонимнарда әдәби норма «ә» кулланылышта булырга тиеш урында, күп очракта Канзәфәр шәҗәрәсе текстында аны «а» сузыгы белән алыштыру күзәтелә. Мәсәлән, Ахмад, Анвар, Хамидулла, Зайнетдин, Хаертдин, Ахмадзаки, Фатхетдин, Валиулла, Хайрулла, Ахмадсафа, Хамза, Хамид, Рашид // Рәшит, Хасан, Фанил, Бадретдин, Ахат, Ахсан, Хайдар, Махмуд һ.б.

Бу күренеш тә бүгенге нугай графофонетик структурасында нык сакланган[3]. Кимрәк күләмдә казак антропонимнарында да моңа охшаш хәлләр күзәтелә. Өлешчә ул казак антропонимнарында авазлар өртелүендә дә чагыла – Анас (Әнәс), Асан (Әсән), Аскар (Әскәр), Асфандияр (Әсфәндияр), Асхат (Әсхәт), Атас (Әтәс), Аухади (Әүхәди), Ахат (Әхәт), Ахмеди (Әхмәди), Ахмет (Әхмәт) һ.б.[4]

Татар әдәби телендә борынгы антропонимнар ясауда кулланылган – гуҗа, – хуҗа компонентлары шәҗәрәдәге исемнәр составында күренми. Бу факт инде әлеге регионда Алтын Урда дәвере өчен хас булган исем калыпларының

---

[2] Җәләй Л. Татар диалектологиясе. – Казан: Татгосиздат, 1947. – 100 б.

[3] Ногайско-русский словарь. – М.: Гос. издат. иностранных и национальных словарей, 1963. – С.485–489.

[4] Жанузаков Т., Есбаева К. Казак есiмдерi. – Алма-Ата: Изд-во «Наука» АН Казахской ССР, 1988. – С.60–66.

әйләнештән төшеп калуына бер мисал. Һәр дәвердә дә исемнәр үз заманына хас булган исем калыплары тудыра. Инде бүгенге казак, нугай, каракалпак, татар антропонимнары базасын чагыштырып караганда да, фактлар анда да Уфадан чыгарылган уйдырма белән, ягъни «төрки тел» дигән билгеләмә белән, реальлек ярашмый.

Канзәфәр шәҗәрәсендәге материалларда исем ясалганда дилабиализация һәм лабиализация күренешләре дә күзгә ташлана. Бу күренешләр бүгенге татар әдәби сөйләм нормаларында чагылса да, алар орфографиядә искә алынмыйлар.

Мәсәлән, шәҗәрәдә Мөхәммәд исеме иренсезләндерелеп – Мехәмәд (Мөхәммәд), Мерзасалих (Морзасалих, Мирзасалих), Юсеф (Йософ), Юнес (Йонос) һ.б. язылганнар.

Иренләштерү очракларына – Караколый, Миңнеколый. Котлобулат (Котлы булат), Котлогилде (Котлы гилде) кебек мисаллар очрый.

Иренсезләшү күренешләре бүгенге Арча-Әтнә якларындагы сөйләштә дә күзәтелә: йигә (өйгә), йирәнәм (өйрәнәм), ыча (оча), ычырма (очырма) һ.б.

Китерелгән шәҗәрәләрнең исемнәр банкы гомуми татар исемнәреннән аерылмый. Шунысы игътибарга лаек, текстта интердентальь «з» авазы куллану очраклары күренмәде. Ихтимал, шәҗәрәне 1967–1970 елларда төзүче Вафин агайның башы алай тенденцияләргә реверанс ясауны кирәк тапмагандыр.

Шәҗәрә текстындагы антропонимнар калыпларын өртүдә катнашкан графофонетик күренешләр бу региондагы татар сөйләшләрен өйрәнүчеләрнең чыгарган нәтиҗәләрен раслыйлар. Мәсәлән, диалектолог галим Д.Б.Рамазанова бу хакта түбәндәге фикерләрне яза:

«Интердентальный «d» встречается редко или вообще отсутствует в населенных пунктах, которые были основаны главным образом служилыми татарами и государственными крестьянами… Миякинского, … Благоварского, … Стерлибашевского, … Белебеевского районов и др.»[5].

---

[5] Рамазанова Д.Б. Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. – Казан: Татар. книж. изд-во, 1984. – С.88.

Йомгак ясап әйткәндә Канзәфәр би шәҗәрәсенең антропонимнары структуралары, ясалыш калыплары ягыннан татар милли исемнәр банкы хәзинәләреннән аерылмыйлар. Аларда очрый торган беркадәр атамалар үзенчәлекләре крайның XVI–XVII гасырлардагы тарихына да һичшиксез ачыклыклар кертер.

Канзәфәр би шәҗәрәсенең тасвирланган тексты һәм аның тарихи кыйммәтен күрсәтүче фактлардан берсе, Канзәфәр бинең XVII гасыр урталарында Нугай Урдасыннан калган Меңнәр кабиләсе ырулары белән берлектә үз илләре өчен Ватан сугышы алып баруын, соңыннан партизан көрәше алып баруы факты булды.

Канзәфәр би исеме Меңнәр шәҗәрәсенең безнең тарафтан табылган төрле текстларында телгә алына[6]. Шәҗәрәләрдә Канзәфәр (Казанфар) бигә бирелгән грамоталардан аңлашылганча, ул XVII гасыр урталарында гомер һәм гамәл иткән кеше була. Ләкин Меңнәр кабиләсе шәҗәрәләрендә күрсәтелгән Канзәфәр бинең балалары текстларда төрле исемнәр белән күрсәтеләләр. Араларында Дистан исемлесе генә күпчелек документларда искә алына.

Вафин Г. китергән риваятьләргә караганда, Канзәфәр дә, Дистан да, басып алучыларга күрсәткән каршылык хәрәкәтендә һәлак булганнар.

Аларның каршылыгын бастыргач андагы татарларның бер өлешен Көнбатышка ассимиляция максаты белән куып алып киткәннәр, яки аларны юлда ук кырып бетерүләре дә мөмкин. 1552–1557 елларда Казанны алгач та шундый депортация ясаган очракларга документлар калганлыгы билгеле[7].

1654, 1667 елгы Польша белән сугышлар вакытында Смоленск һәм Полоцк шәһәрләрен яулап алгач урыслар әсир төшкән поляк дворяннарына җирләр биреп Минзәлә,

---

[6] Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2002. – 106–117 б.

[7] История Татарии в материалах и документах. – М.: Гос. соц. эконом. изд-во, 1937. – С.145–147.

Зәй һәм Кама арьягындагы крепостьларга хезмәткә беркетеп куйганнар.

Нугай Урдасының оккупацияләнгән җирләрендә дә аларны үзләштерү өчен шундый ук сәясәт уздырганлыклары табылган шәҗәрә текстында күренә.

Язма текстның тел ягыннан кыйммәтен саклау өчен шәҗәрәнең орфографиясен төзүче Вафин автографы буенча алдык.

*Марсель Әхмәтҗанов*
филология фәннәре докторы
14.06.2009 елда

## СССР Фәннәр академиясенең Татарстан филиалына тапшырылмакта булган борынгы башкорт «би»ләрендән Канзәфәр би[1] тугрындагы төзелгән шәҗәрәгә теркәлгән мәгълүмат түбәндәгечә

Гәрәй «би» һәм аның углы Канзәфәр «би»ләр Башкортостанның көньяк-көнбатыш илләре белән идарә кылганнар.

Казан мәмләкәте яшәгән чорларда, Казанга табигъ булып, үз исемнәре белән мөстәкыйль идарә кылганнар[2].

Казан жимерелгәндән соң, Рус мәмләкәте белән чиктәш булу сәбәпле, жимерелү нәүбәте шушы ил өстенә төшкән.

Канзәфәр Сарайлы иленең «би»е булып, аның карамагына Бөгелмә яклары, Ак Иделнең көнбатыш жирләре, Дим буйлары, Тукчуран далалары, Җайык йылгасының көнбатышлары керә[3].

Канзәфәрнең торган жире Асылыкүл буйындагы **Кырык Өйле** дигән урында була.

Канзәфәрнең өстенә авырлыклар төшкән чакта Башкортстанның башка «би»ләре үз теләкләре белән Рус патшалыгына бәйгать бирәләр, чөнки, ул заманда, Башкортостанда унбер «би» идарә кылган[4].

Канзәфәр ялгыз кала, җитмәсә Кандра якларында яшәүче борынгы «Мари» вакыйгасы[5], йогынтысы белән мөбталә булган ак сөякләр Канзәфәргә хыянәт итеп, Рус

хөкемдарлыгы белән яшерен элемтә тотып, халык арасында Канзәфәргә каршы өндәмә алып баралар, һәм Канзәфәрнең эше йомшый төшкән, Канзәфәргә каршы патша ягында торып сугышалар[6].

Казан алынгандан соң халыкларны көчләп чукындыру помещикләргә көчләп крестьянлыкка бирү, урманнарны кистереп-яндыру, анда качкан халыкларны карательләр белән аулап алып көнбатыш илләргә сөргенгә озатулардан качкан халыклар Канзәфәргә килеп кушылганнар[7]. Ахырда Канзәфәр юл бирми торган тоташ кара урманнарга яшеренеп көрәшен дәвам итсә дә, уңышка очрамаган. Халык ачлык-ялангачлык, төрле авырулар белән жәфаланып күп кырылганнар. Мәсәлән, бигрәк тә зәңглә авыруына тәкать тота алмаганнар.

Канзәфәр үзе (хәзерге Миякә районы Өязебаш чуаш авылы янындагы) Канзәфәр кулы дигән чокырда яткан. Шул заманнан кала бу урманга Түр урманы исеме бирелгән, ягъни һәр төрле патшалыктан качкан халыклар күп еллар буена Канзәфәр артындагы әлеге урманга агылганнар һәм элегрәк килгәннәре соңрак килгәннәргә, шаярту тәртибендә, әйдә, рәхим итегез, түрдән узыгыз, түрдән. Менә хәзер түрегез шушында «би»егездә шунда дип каршы алганнар.

Канзәфәрнең рәгыятендән башкортлар, татарлар, чуашлар, мукшилар, староверлар, боярлардан качкан башка халык-крәястьяннәр булган.

Ахырда патша гаскәре Канзәфәрләрне камап алып, хәзерге Оло-Каркәле авыл арты территориясендә зур кырылыш булган, кулга алынганнар сөргенләргә куылган.

Шул чорларда хәзерге Миякә, Стәрлебаш һ.б. район территорияләрендә бакыр шахталары булып, аларның рудалары Каркәлетамак авылына күрше булган Имәнлек тауындагы бакыр заводында эшкәртелгән. Ул завод һәм шахталарда кулга алынган татар-башкортлар, рус һәм башка халыклар белән поляк, төрек һәм башка ил пленниләре эшләгән[8].

Монда тәртип шулкадәр каты куелган ки, кечкенә генә гаеп өчен дә 200 гә кадәр розга сугу булган.

Бу бичараларны суккан вакытта, боларның инрәвенә, акыруына этләр өрә торган булган. Өтермә дигән, ягьни төрмә дигән сүз шундан калган.

Шәжәрәдәге Канзәфәр балалары әлеге кырылган, озатылган һәм башкача һәлак булганнарның ятим калган балалар, толлар, гарипләр, карт-корчыклардан үрчегәннәр.

Бу ятим, жәлне гарип-горабаларны тирә-яктагы 12 аул, татар аулы халыклары, миһербанчылык итеп, патшадан яшерен рәвештә тартып алып тәрбиялиләр һәм патша манифистендән соң теләгәннәре хәзерге Каркәлетамак ауылы булып утракланалар.

Боларны тәрбиягә алып, ягьни пропущенныйлеккә алган авыллар шулар:

1. Жыл(ы) былак. 2. Дүсән. 3. Дүсмәт. 4. Таллыбылак. 5. Дим Айыты. 6. Янбак. 7. Шадмантамак. 8. Баязид. 9. Качаган. 10. Сарманай. 11. Качаган. 12. Жилдәр авыллары һәм бу авылларда калганнары шунда яшиләр: алардан: Качаган, Баязид, Шадман, Оло Каркәле һәм Каркәлетамак авылларында яшәүчеләре бу шәҗәрәгә кертелде.

Болар бар да озак еллар татар авылларында тәрбияләнү сәбәпле башкорт телен онытканнар[9].

Шәжәрәгә кергән биш аулның халыклары Канзәфәрнең дүрт улының балалары. Канзәфәрнең биш улы булып – Дистан, Шәйех Хәсән, Шәйех Дирбеш, Абушахмә һәм Туктамышлар.

Шәжәрәне төзүче, мин, Вафин Газиз Мехәмәдвафа угьлы Дистанның тугызынчы буын баласы һәм Канзәфәрнең кылычы, көндәлеге, шәжәрәсе минем атамда саклану һәм мин аның олы угьлы булуым сәбәпле, моны восстановить итү минем бурыч хисаплап, үз теләгем белән һәм Башкортстан Филиалы АН Тел һәм әдәбият бүлегенең киңәше белән эшләдем[10], һәм аларга тәмамлап тапшырдым. Моның өчен 1963 йылдан башлап 1968 елга чикле күп ауылларга сорап һәвәскәр булган бабайлар, әбиләрдән материаллар жыйнадым, чөнки әлеге борыннан калган материалларны ничек тә таба алмадык. Ата-инәләр йәшәгән йорт тузылып беткән. Алай да кылычын революция чорында спектакль уйнарга алып китеп, китермәүләре факт. Башкаларның эзе дә юк.

Әлеге 12 авылның жидесендә мин була алмадым, чөнки алар бездән йөз һәм артыграк еракльткта булып, мин үзем гарип һәм авыру булганлыгымдан, аларга йөри алмадым. Мадди яктан ярдәм итүче булмады.

Канзәфәрнең бишенче улы Туктамыш турында дөрес мәгълүмат таба алмадым. Шулай да бигүк дөрес булмаган имеш сүзләре бар. Имеш. Туктамыш башка башкортларны сөргенгә куганда эләгеп китеп һәлак булган, чама белән әйткәндә, ул вакытта Туктамыш 20 яшьләрдән узмаган булса кирәк.

Шулай да, мин гражданнар сугышы заманында, матур гына белемгә ия булган Туктамышев дигән кешеләр күргән идем. Ләкин, кемләр, кайда икәнен хәтерләмим.

Канзәфәрнең Абушахмә дигән улыннан туган жиденче буын баласы Ермак турында язмак булам. 1916 йылда чыккан «Мәгълүмат» журналында язылуынча, Ермак Абулай угълы башкорт булып Урта Урда Кыргыз казакларының вәли солтаны булып торганында императорның коткысына бирелеп, вәли солтанлыкны ташлап, Урта Урда казак-кыргызларның ханлык дәрәҗәсен кабул иткән һәм Себер ханлыгы өстенә Русия ярдәме белән йөрүе ачыкланды[11].

Ермак баласы Ишкуәт гарәп илләрендә гыйлем алган булса кирәк. Шул замандагы кульязмасын тарих-әдәбият Институтына тапшырдым Уфага. Шулай ук шул замандагы галим Мөхәмәджан мулла Дауд угълы Каличеровның кульязмасын да. Ул язмалар голландский күк киягазга язылган бик нәфис итеп гарәпчә. Китапта Каличеровның адресы да бар: Мехәмәджан молла Дауд углы Каличеров, Петровск волосте, Саратауск губерна, Варшау иле[12].

Ишкуат үзенең кульязмасына «Мин бу китап белән Пекиндә гамәл кылдым», – дип язган.

Ермак Абулай углы вәли солтанлыкны ташлап Урта Урда казак-кыргызларның ханлык дәрәжәсен кабул иткән серимониядә Каличеров тәржеман булган, ягьни переводчик.

Ермак белән Ишкуәтне шәҗәрәдәге исемнәренең астына кызыл белән билге сыздым, сезгә табу жиңел булсын дип. Мехәмәджан мулла Дауд угълы шәжәрәдә юк, чөнки аның Канзәфәр балаларыннан булуына дәлил юк.

Шулай ук Калчировнең кульязмасы нишләп Ишкуәтнеке белән бергә табылсын?

Вәли солтан дигән ләвазимне үзем шулай аңламак булам:

Госманлы төрекләр тарихында губернаторны вәли диләр, ә солтан төрекәрнең патшасы, димәк, Ермак вәли солтан чагында Төркиягә табигъ булган.

Нәтижәгә килик:

Аңлашылмалы булсын өчен, Канзәфәрнең нәселе үрчегән дүрт баласының да араларын кызыл белән әйләндереп күрсәттем. Һәр каюсының нәсел җае хисабын сугыб куйдым ахырына.

Андан соң кайберәүләрне кызыл белән уратып күрсәттем. Мәсәлән, Зәйнегафар, Бакый, Шардай, Бәйрәмголлар – булар 1700–1800 елларда революционный хәрәкәттә кулга алынып, каторгада һәлак булганнар.

Алардан башка кызыл белән уратылган: Фәрхад, Әхмәдшани, Миңнеәхмәд, Миңнебай, Мәхмүд, Габдрахман, Габдерәхим, Баһаутдин һ.б. Булар 1917–1919 елларда Кызыл гвардиядә һәм партизанда һәлак булганнар, алар барсы күпләр, ләкин революция өчен сугышып йөреп, авылга исән кайтканнарны алай күрсәтмәдем.

Тагын бер аңлатма.

Кайбер оруглар, кыягаз кысан булу сәбәпле, үзләре тапкырына сыймау сәбәпле, кызыл белән уратылган номер белән шул тапкыргарак иркенрәк урынга күчереп тәмамланды. Игътибар белән, үз номеры буенча карасагыз шаяд табарсыз.

Мин бу эшне сезгә август аенда хәзерләп тапшырырга вәгъдә куйган булсам да, беразрак вакытлар сәламәтлегем китеп тору сәбәбле, кичектерергә туры килде.

Әгәр бу эш белән кызыксынсагыз, аңлашылмаган урыннары булса, сорап язарсыз, мин җавап бирергә хәзермен, хәлемнән килгән кадәре.

Исәп юлкый алганыгыз турында айырып җәваб язуыгызны үтенәм.

Үзенә күрә байтак ижтиһад кылынганга охшый бит.

Нәтиҗәдә Канзәфәр туздырылгандан соң әлбәттә иленә кайта алмаганнар, шушы Түр урманнарында беглый булып, исән булганнары, йөри биргәннәр.

Канзәфәрләрдән калган жирләрне патша әлеге кушттаннарга бүлеп биреп, аларга дворян хокукы биргән һәм андый хокукка ия булганнар Кандра районында яшиләр.

Алардан башка Бүздәк районында Дистанлылар яши, буларның Канзәфәр балалары белән бер мөнәсәбәтләре дә юк, буларның бабалары, башкортларны Белоруссия, Петербург якларына сөргенгә куган чакларда активлык күрсәтмәгәннәре өчен, Канзәфәрләрнең жирен буларга да бүлеп биреп, үзләрен Дистан фамилиясенә күчереп, патша, Канзәфәр һәм Дистан балалары менә шулар, булар Башкортстанны Русиягә кушкан вакытта патшалыкка күп ярдәмләрдә булдылар, дип ялган документлар төзеп куялар.

Мин бу турыда Бүздәк районына барып, Дистанов Харис дигән агай белән сүләштем һәм ул әйтте:

Мондагы Дистановлар берсе дә Канзәфәр балалары түгел, безнең бабабыз башкортларны көнбатышка куган чакта, патша армиясендә 25 йыл хезмәт иткән һәм башкортларны сөргенгә куу эшендә күп хезмәтләр күрсәткәне өчен, патша аны Дистан фамилиясенә күчереп, Канзәфәрләрнең жиренә хужа иткән, – диде.

Тагы бер аңлатма Катырялан, Зәйнегафар, Бәйрәмгол, Бакый, Мардай бабайларны кыскача гына әйтеп киттем. Аларның да үзләренә күрә мөһим генә тарихлары бар, әгәр кызыксынсагыз, сорап язарсыз. Мин, исән булсам, әлбәттә жавап язармын.

Шардай бабайның бу шәжәрәдә исеме юк, чөнки ул башкорт, ләкин Канзәфәр балаларыннан түгел. Ул мәңгелек каторгага җибәрелгән булып, 48 ел каторгада йөреп, революция аркасында котылып кайткан иде. Мин аны күреп һәм сөйләшеп беләм. Шулай ук Зәйнелгафар бабай белән дә шундый ук хәл.

Инде ахыргы сүз белән, әлеге жәй язып, алып киткәннәр турында айырып язарсыз әле.

Язучы Вафин Газиз Вафа угълы. 5.12.71 (ягъни 1971-нче ел – М.Ә.).

Бу язма күчерелде 14.03.2009 елда.

**Искәрмәләр**

[1] Канзәфәр би – әгәр башкорт бие булган булса, ул баш күтәреп, урыслар белән сугышып йөрмәс иде, ул Нугай Урдасының Меңнәр кабиләсенең бие булган. Вафин Г. Бу урында Уфадагы тарих, тел һәм әдәбият институты хезмәткәрләре биргән консультация буенча гамәл итә.

[2] Димнең югары агымында Казанга бәйле административ бәйләнеш булуы бик шөбһәле. Бу җирдә XVII гасыр урталарына кадәр Нугай Урдасы биләре хакимлек итеп торганнар.

[3] Канзәфәр би Сарайлы иленең генә түгел, Нугай Урдасының да бие.

[4] XVII гасырда түгел, 1919 елга кадәр бернинди Башкортостан дигән сәяси-административ бүленеш булмый. Нугай Урдасы Агыйдел һәм Кама елгаларының сул як җирләрендә хуҗа булып тора. Мәскәү кнзяьлегенең чик буе итеп 1650–1670 елларда Минзәлә, Ерыклы, Зәй, Сембер ныгытмалары корып йөрүе шуның дәлиле. Хәтта ки Нугай Урдасыннан калган татарлар белән Урал буйларына Казан губернасыннан анда качып килеп утырган татарларның Оренбург, Сакмар ныгытмаларын төзеттермәс өчен 1735–1741 елдагы сугыш алып барулары, Нугай Урдасы халкының Урал буйларында Мәскәүгә кушылырга теләмәгәнлеген күрсәтү чарасы булып тора.

[5] «Мари» вакыйгасы... – бу проблема әлегә аңлашылмый, тарихи чыганакларга ихтыяҗ бар.

[6] Мәскәү хөкүмәте Урал буйларында «бишенче колонна» булдырып, Нугай Урдасы халкын үзара каршы куюга ирешкәнлеге күренә.

[7] Бу фактлар XVIII йөзгә кергәч Русия хөкүмәте тарафыннан уздырылган сәясәтнең җирле тарихи анда чагылышы булып тора, чөнки XVII йөздә әле урманнар кисепяндырылып завод-фабрикалар эшләтү дәвере түгел.

[8] Бу язылганнар XVIII гасыр вакыйгаларына карыйлар, XVII гасыр уртасы Канзәфәр би заманында түгел.

[9] Бу вакытларда башкорт теле Нугай Урдасы җирләрендә була алмый. Шәҗәрәдәге исемнәрнең орфографик үзенчәлекләре Нугай Урдасы татарларының тел үзенчә-

лекләре әле XX гасырның 70-нче елларына кадәр тулы бер система буларак сакланганлыгын күрсәтә. Китерелгән фикер Уфадагы филолог галимнәрнең уйдырма заказын үтәүнең бер чагылышы һәм татар халкына карата яла ягу булып тора.

[10] Вафин Г. Уфа галимнәренең явыз заказ бирүләрен үтәүе хакында үз каләме белән язып калдырган. Бу кеше намуслы бер адәм булып ялган тозагына эләккән.

[11] Казаклар арасында «башкорт» Ермак Абулай улының вәли солтан һәм хан булып торуы бик шөбһәле, чөнки казакларга башкортларны котыртып, аларга һөҗүм итеп йөрүләренә мөнәсәбәттә, алар кешесен хан итеп кую казаклар өчен хас түгел. Ермак Абулай улы үзен «нугай» дип атаганы өчен генә мондый вакыйганың булуы мөмкин.

[12] Бу абзацта искә алынган кешеләр башкорт сословиясенә эләгеп йөргән нугай татарларының токымнары икәнен шәҗәрәдә документ нигезендә күрсәтелде.

Искәрмәләрне текстолог
*Марсель Әхмәтҗанов* язды

## КАНЗӘФӘР БИ ШӘҖӘРӘСЕ

### Канзәфәр би шәҗәрәсенә кереш сүз

1500–1700 йыллардагы, хәзерге көньяк-көнбатыш Башкортостан кешеләренең ахвалләре һәм андагы биләрнең токымнары турындагы мәгьлүмат шәҗәрәсе. Төзелде 1963–1970 йылларда Каркәле-тамак ауылы гражданы Вафин Газиз Мөхәммәдвафа углы тарафыннан түбәндәгечә:

Гәрәй «би» → Канзәфәр би. Түбәндә Канзәфәр «би»нең балалары. Алар яшиләр Оло-Каркале, Каркале-тамак, Качыган, Баязид, Жилдәр, Шадмантамак ауылларында. Дим Айыты, Жыл(ы)болак, Таллыболак, Дүсән, Янбак, Сарманай аулларында яшәүчеләр бу шәҗәрәгә кертелмәде. Шулай ук Жилдәр ауылында яшәүчеләр дә данный бирмәүләре сәбәбле кертелмәде. Гәрәй «би»нең аның баласы Канзәфәр «би» аның балалары.

## № 1. Дистан (Канзәфәр бинең беренче улы)*

**I буын**
1. Дистан

**II буын**
2. Сәрмехәмәд 1

**III буын**
3. Шайморад 2

**IV буын**
4. Аптек-Абдула 3

**V буын**
5. Фәйзулла 4
6. Гаделша 4 (Аның токымнары аерым таблица итеп бирелде)

**VI буын**
7. Фәтхулла 5
8. Бахтияр 5
9. Зайнулла 5
10. Зайнегабид 5

**VII буын**
11. Галиулла 7
12. Сафиулла 7
13. Корбангали 7
14. Арслан 8
15. Сөбханкол 8
16. Зөбәйдулла 9
17. Хамидулла 9
18. Хасретдин 10
19. Зайнетдин 10
20. Зайнулла 10

**VIII буын**
21. Могтасимша 12
22. Мехәмәдсафа 12
23. Мехәмәдвафа 12
24. Солтангали 13
25. Нургали 13
26. Ханжгали 14
27. Муллагали 14
28. Исламгол 15
29. Шаһимәрдән 16
30. Ахмадсафа 16
31. Хайрулла 17
32. Гизатулла 17
33. Сөләйман 17
34. Ахмадзәки 17
35. Хужиахмад 17
36. Габделжалил 17
37. Логман 17
38. Гариф 19
39. Каррам 19
40. Габдельгафар 20
41. Фатхетдин 20
42. Гайнетдин 20
43. Валиулла 20
44. Зинур 20

---

* Исемнәрнең сул ягындагы саннар аның шәҗәрәдә ничәнче урында булуын күрсәтә. Уң яктагы саннар аның шәҗәрәдә атасының сул якта ничәнче сан белән күрсәтелүен белдерә. Буыннар төркеме шәҗәрәдәге исемнәрнең кардәш кешеләрнең кордаш, замандаш булуларын күрсәтә.

## IX буын

45. Гаделша 21
46. Хамза 22
47. Хамид 22
48. Мажид 22
49. Габдельгазиз 23
50. Габдельфаттах 23
51. Гомәр 23
52. Имаметдин 23
53. Рәшид 23
54. Шамыйл 23
55. Ибраһим 24
56. Масалим 24
57. Хаереннас 24
58. Фарваз 25
59. Ямалетдин 25
60. Ахмадвали 25
61. Миргани 26
62. Габдельгали 27

63. Миңнеахмад 27
64. Исмәгыйл 28
65. Шәйхелислам 28
66. Шириаздан 29
67. Хасан 29
68. Суфьян 29
69. Гимран 29
70. Галимрахман 30
71. Миңнегали 31
72. Миңнебай 31
73. Гомәр 33
74. Мансур 33
75. Габдулла 33
76. Бакыйр 34
77. Яриахмад 35
78. Коддус 36
79. Габделбарый 36
80. Сабирян 37
81. Шакирян 37
82. Ярулла 37
83. Зариф 38
84. Зөфәр 39
85. Фанил 39
86. Габделькаюм 40
87. Габделмажид 40
88. Бадретдин 41
89. Имаметдин 41
90. Габдулла 41
91. Фатхулла 41
92. Габдулла 43
93. Габидулла 43
94. Фазашахма 43

## X буын

95. Зия 45
96. Рифгат 46
97. Заригат 46
98. Магфур 46
99. Ханиф 47
100. Риф 47
101. Рәүф 47
102. Зинур 47
103. ? 48
104. ? 48
108. Ильфак 49
109. Рәис 51
110. Рәфис 51
111. Иршад 53
112. Рафаил 55
113. Рәис 55
114. Гайнетдин 63
115. Миңнетдин 63
116. Миннебай 64
117. Исраил 64

105. Ахтам 49
106. Анвар 49
107. Ахат 49
118. Ахсан 67
119. Васим 68

120. Варис 68
121. Васим 68
122. Талгат 68
123. Асгат 68
124. Махмуд 68
125. Вагиз 68
126. Камиль 69
127. Хайдар 69
128. Зия 77
129. ? 77
130. Вазих 80
131. Рәис 83
132. Наил 83
133. Забир 84
134. Иршад 89
135. ? 91
136. Ахат 92
137. Гайфулла 93
138. Васидахмад 94
139. Махмуд 94

**XI буын**

140. Радик 121
141. Таврис 123
142. Рөстәм 124
143. Мансур 124
144. Расуль 124
145. ? 130
146. Фәрит 137
147. Фатхулла 137
148. Вагиз 138
149. Ильмир 138

**XII буын**

150. Ринад 147
151. Риф 147

**Гаделша нәселе тармагы кушымта итеп төзелә**

**V буын**

6. Гаделша 4

**VI буын**

7. Ниязгол 6

**VII буын**

8. Кинжагол 7
9. Азангол 7
10. Рахимкол 7

**VIII буын**

11. Габдулла 8
12. Мехәмәдсадик 9
13. Садретдин 9
14. Галяметдин 10

## IX буын

15. Габдрахман 11
16. Хабибрахман 11
17. Лотфырахман 11
18. Зариф 12
19. Зариф 13
20. Фаез 13
21. Газиз 13
22. Сайфетдин 14
23. Саяхетдин 14
24. Фарахетдин 14
25. Баһаутдин 14
26. Камалетдин 14
27. Фатхатдин 14
28. Сахабетдин 14

## X буын

29. Габделхамид 15
30. Габдельмажид 15
31. Габдельгазиз 15
32. ? 16
33. Гирфан 18
34. Вильдан 18
35. Гариф 19
36. Зәки 19
37. Малих 20
38. Габдрахим 21
39. Бари 21
40. Асхабетдин 22
41. Агляметдин 22
42. Караметдин 22
43. Габдулла 22
44. Габделбари 22
45. Садретдин 22
46. Фасхетдин 23
47. Шайхетдин 23
48. Хакетдин 24
49. Зәйнелгабит 24
50. Фаттахетдин 24
51. Мифтахетдин 24
52. Габдрахман 25
53. ? 25
54. ? 25
55. Насыйх 26
56. ? 26
57. Муса 27
58. Гомәр 27
59. Хамид 27
60. Хасан 28
61. ? 28

## XI буын

62. Габделхай 31
63. Заригат 33
64. Хайдар 33
65. Логман 34
66. Хабибжан 34
67. Гарифжан 34
68. Ахтам 38
69. ? 38
70. Хисаметдин 40
71. Ямалетдин 40
72. Анвар 42
75. Амин 48
76. Флюр 48
77. Наил 48
78. Кашиф 48
79. Ахат 49
80. Рәис 49
81. Габделхай 50
82. Зариф 50
83. ? 50
84. Махмуд 51
85. Госман 51

73. Зия 42
74. Шамыйл 42
86. Шакир 51
87. Габдельбари 51

**XII буын**

88. Хайдар 81

## № 2. Шәйех Хәсән (Канзәфәр бинең икенче улы)

Шәйех Хәсән – Ихсан – Хасби – Тукай – Ахтам – Сәерюл.

**I буын**

1. Сәерюл

**II буын**

2. Адһам 1
3. Сәергази 1

**III буын**

4. Жагфар 2
5. Саедбаттал 2
6. Габдрахман 2

**IV буын**

7. Габделгафар 4
8. Зәйнегафар 4
9. Билал 5
10. Шәйхелислам 5
11. Садрислам 5
12. Газиан 6

**V буын**

13. Габделжабар 4
14. Ихсангали 8
15. Миңнегали 8
16. Баһлул 9
17. Галяутдин 9
18. Бадретдин 9
19. Шамсиислам 10
20. Вали 10
21. Зайнула 11
22. Габдсалям 11
23. Саедислам 11
24. Миңнегол 11
25. Гобәйдулла 11
26. Сөләйман 12
27. Локман 12
28. Миһран 12
29. Миңнебулат 12
30. Вилдан 12

**VI буын**

31. Хажвәли 15
32. Ахмадвали 15
33. Саяфетдин 16
34. Баһаутдин 16
35. Миңнебай 17
36. Миңнегали 17
46. Габдрахим 27
47. Бәхетгали 27
48. Габдельгалим 27
49. Миңневали 27
50. Заһретдин 27
51. Адһам 28

37. Бадготдин 18
38. Хоботдин 18
39. Мансур 25
40. Хакимян 26
41. Гилман 26
42. Гирфан 26
43. Салман 26
44. Салимян 26
45. Хасанжан 26
52. Жиһангир 28
53. Логман 28
54. Миңлеколой 29
55. Миңлегали 29
56. Газизян 30
57. Рахимян 30

**VII буын**

58. Ихсангали 32
59. Вагиз 32
60. Баһаутдин 33
61. Барис 34
62. Рамил 34
63. Рашид 34
64. Миңнеколой 37
65. Агляметдин 37
66. Равел 37
67. Рәжәб 37
68. Забир 38
69. Сабит 38
70. Зайни 38
71. Гаяз 38
72. Газизян 40
73. Госман 41
74. Гайнан 41
75. Шакирян 41
76. Газизян 41
77. Сабирян 42
78. Рәшид 42
79. Хасанян 43
80. Сагидян 44

**VIII буын**

81. Рәжәб 66
82. Рәшид 66
83. Абузар 73
84. Амин 73
85. Малван 74
86. Мохтар 74
87. Вакил 75
88. Варис 75
89. ? 77
90. Рим 79
91. Ильдар 79

## № 3. Шәйех Дирбеш (Канзәфәр бинең өченче улы)

Канзәфәрнең өченче улы Шәйех Дирбеш балалары бик күп булу сәбәпле, арт яктагы өченче урынга сыймады, (текст язылган кәгазь турында сүз бара – М.Ә.) шунлыктан бу якка күчерергә туры килде. Ул өченче урынга Канзәфәрнең дүртенче улы Абушахма балалары язылды.

Канзәфәр «би» углы № 3 Шәйех Дирбеш балалары Бишбау → Ишмөхәммәд → Ишморад → Тимерхан → Габдерәкыйб → Габделвахид → Габделкәрим → Хөбетдин → Фәтхетдин.

### I буын

1. Габделвахит балалары

### II буын

2. Динислам 1
3. Габдессәлам 1
4. Галиулла 1
5. Габдельнаф 1
6. Габделмәннаф 1

### III буын

7. Нәдерша 2
8. Яхия 2
9. Миннебай 2
10. Айчувак 2
11. Габделкәрим 3
12. Гайнетдин 4
13. Рахматулла 4
14. Галиулла 4
15. Газизулла 4
16. Шайхетдин 4
17. Халим 4
18. Габдерәүф-Хәким 5
19. Сахибгәрәй 6
20. Шаһиахмад 6
21. Шайхислам 6

### IV буын

22. Нәдерша балалары аерым, нәсел итеп күрсәтелде
23. Гале
24. Габделмоталап 9
25. Габдрахман 9
26. Өмидбай 9
27. Исмагыйль 9
28. Нургали 10
29. Мирсаяп 10
30. Тимербулат 10
31. Акбулат 10
32. Габдерәфик 11
33. Зәйнелгафар 11
34. Төхфәтулла 14
35. Калимулла 14
36. Миңнетдин 14
37. Миңнулла 14
38. Нигматулла 14
39. Лотфулла 14
40. Хабибулла 16
41. Фасхетдин 16
42. Фатхетдин 16

43. Миңнеахмад 16
44. Фәнис 17
45. Габдельхак 18
46. Габдельнагим 18
47. Габделькадир 18
48. Миңнеахмад 18
49. Нуриахмад 18
50. Шайхислам 19
51. Шаһиахмад 19
52. Мехәмәдгәрәй 19
53. Ахмад 21
54. Ахмаделислам 21

## V буын

55. Иркабай 26
56. Асфандияр 27
57. Салих 27
58. Искандар 27
59. Миңнеахмад 29
60. Акдавлят 29
61. Гизетдин 30
62. Миңнебулат 30
63. Миңһажетдин 30
64. Мерзасалих 30
65. Сарвар 30
66. Ахмадулла 31
67. Миңнегол 31
68. Сагидулла 31
69. Зиннур 32
70. Рәфик 32
71. Тәмербәк 33
72. Мирмокыйм 33
73. Хайрбашар 33
74. Хакамбәк 33
75. Мирхәйдәр 33
76. Габдельгафар 33
77. Һибатула 34
78. Калимула 34
79. Нигматула 34
80. Лотфула 34
81. Равел 40
82. Сабир 41
83. Хабибулла 41
84. Вали 41
85. Алим 42
86. Васил 42
87. Рәшад 42
88. Нияз 42
89. Тамурбәк 45
90. Габделгазиз 46
91. Ахмадгали 45
92. Габдельгани 46
93. Габдельхалим 46
94. Габдельгалим 46
95. Габдельнасыйр 46
96. Габдельхабир 47
97. Габделькабар 47
98. Габделькарим 47
99. Габдулла 48
100. Габдельфәһем 49

101. Кияметдин 49
102. Ахмад 50
103. Ахмадрислам 50
104. Бахтегәрәй 52
105. Вагиз 52
106. Заһид 52
107. Канзафар 54

## VI буын

108. Гильмулла 55
109. Миңнебай 55
110. Ахмадгәрәй 56
111. Миңнеяр 56
112. Мәүлеяр 56
113. Ахмадгали 57
114. Фатхелислам 58
115. Шамселислам 58
133. Марс 68
134. Закир 69
135. Шарафетдин 69
136. Насыйб 69
137. Миңнегали 70
138. Шафик 70
139. Габдерәфик 70
140. Габдерәүф 72

116. Миргали 60
117. Фатхетдин 61
118. Галяутдин 61
119. Бадретдин 61
120. Имаметдин 61
121. Корбангали 61
122. Миңнегали 61
123. Агляметдин 62
124. Логман 62
125. Инсаф 62
126. Тәмербәк 64
127. Рәшид 64
128. Сабирян 65
129. Рәшид 67
130. Рәис 67
131. Маннаф 68
132. Касыйм 68
141. Арсланбәк 72
142. Мифтахетдин 73
143. Кияметдин 73
144. Мортаза 74
145. Сахиулла 74
146. Башарбәк 74
147. Мөхсин 75
148. Габдулла 75
149. Камыйл 75
150. Ихсан 76
151. Габдр...аб 76
152. Габдельхабир 76
153. Габдрәхим 76
154. Миңнеахмад 77
155. Гобәйдулла 78
156. Байтурә 79
157. Салыйх 80

158. Габдерәшид 80
159. Миңнебай 89
160. Миңнеислам 89
161. Тимербай 89
162. Рифат 92
163. Талгат 92
164. Рамил 92
165. Зия 92
166. Шаукат 92
167. Мансур 93
168. Риф 93
169. Рим 93
170. Ахтам 94
171. Миңнехәй 94
172. Шамыйл 97
173. Махмуд 98
174. Ахат 98
175. ? 98
176. Фанис 99
177. Рәфис 99
178. Канзәфәр 102

**VII буын**

179. Хамидулла 105
180. Газизулла 105
181. Хабибрахман 106
182. Сабир 107
183. Рәис 107
184. Миңнебай 108
185. Габделсамад 109
186. Габдрахим 109
187. Гомәр 109
196. Агзам 119
197. Мансур 119
198. Вагиз 121
199. Рәис 123
200. Амирҗан 125
201. Ильяс 131
202. Ибраһим 131
203. Госман 132
204. Махмүд 132

188. Нурислам 111
189. Фаил 114
190. Хөснетдин 115
191. Зөфәр 117
192. Тамимдар 118
193. Рәис 118
194. Васил 119
195. Гәрәй 119

205. ? 132
206. Хамидулла 133
207. Миңневали 134
208. Миңнебай 134
209. Сарвар 135
210. Миңнетдин 136
211. Миңнекәй 136
212. Рәсим 136

213. Ахмидвали 137
214. Нияз 138
215. Магмун 138
216. Анвар 139
217. Миңнеахмад 139
218. Заһри 140
219. Газиз 140
220. Таврис 141
221. Ахмад 142
222. Анвар 142
223. Габдарахман 147
224. Габдельхәлим 149
225. Габдрәфик 150
226. Габдессаләм 150
227. Миңнеахмад 150
228. Гайнулла 152
229. Лотфулла 152
230. Миңнегәрәй 152
231. Галимрахман 153
232. Мөнир 176
233. Зинур 176
234. Васил 176
235. Фанил 176

236. Фәнис 177
237. Васим 187
238. Хәйрнас 192
239. Ильяс 193
240. Ильдар 193
241. Гилязетдин 198
242. Фатхетдин 198
243. Мөдәрис 201
244. Альберт 201
245. Рәшад 202
246. Давыт 204
247. Миңнеахмад 204
248. Фаез 218
249. Файзулла 218
250. Гобәйдулла 218
251. Флюр 219
252. Фәнис 220
253. Варас 220
254. Салават 220
255. Миңнегали 220
256. Юрис 220
257. Минневали 220
258. Рөстәм 221

## Бер өстәмә
## Ахунян

1. Шарифжан 1
2. Шакирян 1
3. Басыр 1
4. Сахеп 1
5. Агьзам 2

## № 4 Абүшахма (Канзәфәр бинең дүртенче улы)

Абүшахма → Ахмуд, Балтач, Габбас, Аксарый, Байсарый, Комай, Абулай, Ермак, Ишкуат

### I буын

1. Мехәмәджан

### II буын

2. Мифтах 1
3. Хафиз 1
4. Могаттар 1

### III буын

5. Гыйльметдин 2
6. Галяметдин 2
7. Борһанетдин 2
8. Минһажетдин 2
9. Фатхетдин 3
10. Жалалетдин 3
11. Кашафетдин 3
12. Саяхетдин 3
13. Шайхата
14. Ялакай 4

### IV буын

15. Биктимер 6
16. Тимергали 6
17. Фахретдин 7
18. Баһаутдин 7
19. Мисбахетдин 7
20. Юсеф 7
21. Юнес 7
22. Сәйфелмулюк 7
23. Габделкаюм 8
24. Габделвахид 8
25. Мехәмәд 9
26. Зәнгабид 9

27. Сахабетдин 9
28. Шарафетдин 11
29. Фәрвазетдин 11
30. Фаттахетдин 12
31. Габдельбари 12
32. Тахаутдин 12
33. Габделһади 12
34. Мехәмәдгәли 13
35. Мостафа 13
36. Гилакай 14

### V буын

37. Миңнеяр 15
38. Корбангали 15
39. ? 16
40. Корбангали 19
41. Хисаметдин 19
42. Камалетдин 19
54. Билал 28
55. Хисаметдин 29
56. Сарваретдин 29
57. Гаяз 29
58. Мөнир 29
59. Дирбеш 30

43. Исмагил 21
44. Зия 21
45. Ахнаф 23
46. Кияметдин 23
47. Инсафетдин 23
48. Газизйан 26
49. Камалетдин 27
50. Садыйк 27
51. Хабибрахман 27
52. Инсаф 28
53. Касыйм 28
60. Шамсун 30
61. Мифтах 30
62. Назыйф 31
63. Талха 31
64. Гаяз 32
65. Ринат 33
66. Садыйк 35
67. Габид 35
68. Фәррах 36
69. Зиякай 36

**VI буын**

70. Рамил 40
71. Касыйм 52
72. Фанис 54
73. Рафаил 60
74. Ильдар 62
75. Альберт 63
76. Камил 66
77. Вакиль 66
78. Гимакай 69

**VII буын**

79. Радик 77
80. Тимерхан 77

**VIII буын**

81. ? 80

## Өченче буындагы Жалалетдин Хафиз улы тармагына өстәмә

**II буын**

3. Хафиз 1

**III буын**

10. Жалалетдин 3

**IV буын**

11. Галяутдин 10
12. Габдрахман 10
13. Низаметдин 10
14. Мөхсин 10

**V буын**

15. Миңнеяр 11
16. Салахетдин 11
17. Рәис 12
18. Ахтам 12
21. Миңнетдин 13
22. Заригат 13
23. Амин 13
24. Медаги 14

19. Расим 12
20. Мехәмәд 13
25. Васим 14
26. Зөфәр 14

**VI буын**

27. Риф 16
28. Рафис 16
29. Таврис 17
30. Рамел 24
31. Равел 24
32. Рәшид 24
33. Миңнехәй 25
34. Урал 26
35. Жагъфәр 26

## Абүшахмә нәселеннән № 4 улы

**I буын**

1. Абүшахма

**II буын**

2. Балтач 1

**III буын**

3. Караколый 2

**IV буын**

4. Биктимер 3
5. Мозафар 3

**V буын**

6. Миңнеколый 4
7. Маннаф 5
8. Котлобулат 5
9. Котлогилде 5
10. Зайнегафар 5
11. Галием 5

**VI буын**

12. Юнес 6
13. Асфандияр 7
14. Бахтегәрәй 7
15. Сытдыйк 7
16. Мехәмәдьяр 7
17. Муллашакир 8
18. Гафур 8
19. Таһир 9
20. Закир 9
21. Лотфрахман 11
22. Хабибрахман 11
23. Габдрахман 11
24. Габдельмоталлаб 11
25. Алдар 11

**VII буын**

26. Миңнебулат 12
27. Галяутдин 12
28. Хакетдин 12
29. Котлогер 13
30. Давлетгәрәй 14
33. Хайрвафа 16
34. Габдельгали 17
35. Миңнеяр 17
36. Заки 17
37. Гомәр 17

31. Хажи 15
32. Мехәмәдгәли 15
38. Габдельхак 18
39.Фатих 18

40. Вакил 19
41. Вазир 19
42. Фазрахман 21
43. Хөснеррижал 22
44. Хәбибрижал 22
45. Лотфула 23
46. Галимрахман 23
47. Габдракиб 24

**VIII буын**

48. Баһаутдин 27
49. Галяметдин 27
50. Шарафетдин 27
51. Саляхетдин 28
52. Хоботдин 29
53. Саедбатал 29
54. Мөхитдин 29
55. Хайрулла 29
56. Риси 31
57. Ирек 31
58. Рөстәм 31
59. Наил 32
60. Анвар 32
61. Камыйл 32
62. Ахат 34
63. Асгат 34
64. Анвар 37
65. Мозафар 42
66. Файруз 43
67. Хасан 44
68. Хөснерижал 44
69. Мостафа 45
70. Вали 45
71. Гобәйдулла 47

**IX буын**

72. Ильдус 51
73. Мөсавир 52
74. Вазир 52
75. Жалил 52
76. Заһид 53
77. Салих 53
78. Садыйк 53
79. Ярулла 55
80. Миңнебай 55
81. Муса 65
82. Маннур 65
83. Масгут 69
84. Мөхәррәм 69
85. Мехәмәд 69
86. Сәгадәт 69
87. Салават 69
88. Махмуд 69
89. Рафаил 70
90. Радик 70
91. Габдрахман 71
92. Азнабай 71

**X буын**

93. Гатаулла 91
94. Габделхак 91
95. Габделваһаб 91

## XI буын

96. Фарваз 93
97. Якуп 93
98. Галимулла 93
99. Шакир 94
100. Зөфәр 94

## XII буын

101. Газизулла 95
102. Габдесамат 95
103. Габделвали 95
104. Гобәйдулла 95
105. Габдерәүеф 95
106. Ибраһим 95

## XIII буын

107. Миңнетдин 104
108. Габдулла 104
109. Мосавир 104
110. Закиулла 105
111. Габдрахман 105
112. Габделхай 105
113. Габдулла 106
114. Исмагил 106

# ШӘЙЕХ ДИРБЕШ ШӘҖӘРӘЛӘРЕ

## Беренче кулъязма тексты

### *Шәйех Дирбеш шәҗәрәсенең Төмбарлы кулъязма тексты*

Бу кулъязма текстны Татарстан Республикасының Баулы төбәге Исергәп авылыннан укытучы Шагалиев Гали ага 1992 елда табып җибәргән иде. Кулъязма Баулы төбәге Акбаш авылында табылган.

Шәҗәрә зурлыгы 52х68 см зурлыктагы Казанда мануфактура һәм милли баш киемнәре җитештереп сатучы сәүдәгәр Гайнетдин Сабитовның товарлар төреп сату өчен чыгарылган фирменный кәгазенең ике ягына тутырып язган тексттан гыйбарәт.

Кәгазь юка, шактый пычранган һәм бөкләнгән урыннардан өзелгән яки өзелеп чыгарга җиткән. Урта урыннарында да өзелеп югалган ертык-тишекләр бар. Сабитов Гайнетдин (1858–1917 елдан соң) сәүдә ширкәте 1886 елдан соң оештырыла. Аның киңәеп, танылып китүе XX йөз башына карый. Бу шәҗәрә язылган фирменный кәгазе дә шул XIX йөз ахыры XX йөз башларында, сәүдәнең культурасын үстерү максатында чыгарылган.

Шәҗәрә тексты имән каерысыннан ясалган коңгырт кара белән язылган. Аның төзелеше катлаулы бердәм стерженын тотып алу кыен. Ихтимал аны язучының кәгазь проблемасы булып, ул текстны, текстны бик тыгызлап язу ысулы белән максатына ирешкән.

Шәҗәрә бабаларыннан бары Шәйех Дирбештән башлап кына аның реаль тарихы да башлана. Нәселне XVIII–XIX гасырдагы шактый нәсел тарихларына мода булып кергән Адәм галәйһиссәлам балаларның ялгау традициясе монда да күзгә ташлана. Әлбәттә бу мәгълүмат та мөһим, ул тарихи кыйбланың тарихтагы юнәлешләрен ачыкларга ярдәм итә. Шәҗәрәдә Шәйех Дирбешнең атасы итеп атаклы суфый Миркамал күрсәтелә. Миркамалның ата-бабаларының чылбыры өзеклекләр белән (чөнки кулъязмада

аерым урынның ертылып берничә буыннар арасында бәйләнеш югала. – М.Ә.) түбәндәгечә бара – «...әли Йармөхәммәд углы, Йармөхәмәмд Ду Хаҗи Әхмәд углы (ягъни ике тапкыр хаҗга бар була. – М.Ә.), Ду Хаҗи Әхмәд Аста дийербез – Шәйех Аста суфый углы, Аста суфый Хаҗи Хәлалем углы, Хаҗи Хәлалем Баҗа шәйех углы [...] Садыйр углы, Садыйр Сәлман углы. Бисмиллаһи-р-рәхман әр-рәхим [...] шәҗәрәдән күчерелмеш купийәдер. Кадим бабалардан рөхсәт калмышдыр, йа сөннәтмидүр, йа важибмидүр [...] купыйдыр. Йире Төркестан йирликдүр, Сәлиман... җ бабадыр, андыйн Аста суфый бабадур, андҗыйн ... Баҗа шәйех бабадыр [...], андыйн аның углы бән йазгучы ... Габделвахид бабадыр».

Йәһүдә углы Йосыф
Йосыф углы Мотыйг
Мотыйг углы Әмәт
Әмәт углы Нәҗәт
Нәҗәт углы Халис
Халис углы Хамуа
Хамуа углы Наху
Наху углы Гаму
Гаму углы Йунан
Йунан углы Мөлек
Мөлек углы Лави
Лави углы Мотыйб
Мотыйб углы Һали
Һали углы Йосыф
Йосыф углы Гыймран
Гыймран кызы Хәзрәте Мәрьям
Хәзрәте Мәрьям углы Гайсә г-м.

**Шәйех Дирбешнең бер углы Турай**. Турайның беренче углы Мәчтәк, Мәчтәк углы Мамык, Мамык углы Туйгуҗа, Туйгуҗа углы Шәфи Төмбарлыда.

**Йәнә Шәйех Дирбешнең икенче углы Туктамыш**. Туктамышның беренче углы Ардык, Ардык углы Зайыт, Зайыт углы Ишәй, Ишйә углы Чәчәң Турайда.

**Йәнә Шәйех Дирбешнең өченче углы Тутай.**

**Шәйех Дирбешнең дүртенче углы Каһарман.** Каһарманның углы Йимангол.

**Шәйех Дирбешнең бишенче углы Тукбирде.** Тукбирде углы Уразай. Уразай углы Туктагыл, Туктагыл углы Йулдаш.

**Шәйех Дирбешнең алтынчы углы Буйкә**. Буйкә углы Йәнә Мөхәмәмдгол, Мөхәмәмдгол углы Бикчәнтәй, Бикчәнтәй углы Мәхсүд, Мәхсүд углы Хәлил, Хәлил углы... Хәлилнең икенче углы Габдерәфыйк, янә Хәлилнең өченче углы Габделлатыйф, янә Хәлилнең дүртенче углы Габделвахид.

Габделвахидның беренче углы Габделхәбир, икенче углы Гыймадетдин, өченче углы Шәмсетдин, дүртенче углы Бәдретдин, бишенче углы Җамалетдин.

Габделвахидның алтынчы углы Фәхретдин, җиденче углы Баһаветдин.

Бәдретдин углы Хәлфетдин.

Хәлфетдин углы Әхмәдзәки.

Хәлфетдиннең икенче углы Миргалим, Миргалим углы Миргабид.

Габделлатыйфның беренче углы Габделкадыйр, икенче углы Гыйлаҗетдин, өченче углы Җәлалетдин.

**Шәйех Дирбеш бабаның җиденче углы – Ырыс**. Ырыс углы Мәрдаш. Мәрдаш углы Санай. Санай углы Арслан. Арслан углы Габдерәшид, аның углы Йүзәй, Йүзәй углы Зөбәйер, Зөбәйер углы Гозәйер. Гозәйер углы Әхмәдшаһ. Әхмәдшаһ углы – берсе Фарукша, аның углы Мингәрәй; икенчесе Бәширзадәт. Бәширзадәтнең беренче углы Мирсәлим, икенче углы Мөхәммәдгариф, өченчесе Шәйхулла, дүртенчесе Мөхалләсаһи. Шәйхулал углы Шәйех Мансур.

Нәселнең бу тармагы Төмбарлыда киселә.

Мәзкүр Зөбәйернең углы Гозәйернең икенче углы Хәйерелбәшар, Төмбарлыда. Аның улы Бәдри, Бәдридән туган Габбас, Мирхәйдәр. Хәйерелбәшардан икенче угыл Габделгаффар.

**Шәйех Дирбеш бабаның сигезенче углы Байсубы**. Байсубы углы Бийбулды, Бийбулды углы Бийморза, Бийморза углы Солтанай, Солтанай углы Йөркәй, Йөркәй углы әүвәл баш Әмирхан.

**Әмирхан тармагы.** Әмирханның баш, беренче, углы Хәбибрахман, икенчесе Игътисам, өченчесе Ширийаздан, дүртенче Мөхәммәдшаһ, бишенче Тәминдар, алтынчы Хәйдәр, җиденче Хәсән.

Әмирханның икенче углы Игътисам, аның углы Вәлид, Вәлидтән Әхмәд, Мостафа.

Ширийаздан, Шаһимәрдән.

Әхмәдтән туган Әхмәдгәрәй, аннан туган Мөхәммәдгәрәй.

Мостафадан туган Миңнехарис.

Ширийздандан туган Шаһигоман.

Шаһимәрдәннән туган Шакирҗан. Икенче Сәлимҗан, өченче углы Миңнеҗан, дүртенче углы Мирсәйед, бишенче углы Мирзаһид, алтынчы углы Нурсәйед.

Мөхәммәдшаһтан туган Мәрдәнша һәм Шаһигоман.

Шаһигоман углы Җиһангәрәй, Миңнехан.

Тәминдар углы Шакирҗан.

Хәйдәр углы Сәлимгәрәй, Мөхәммәдгәрәй, Сәйедгәрәй.

Сәлимгәрәй углы Сахибгәрәй.

Мөхәммәдгәрәй углы Мәмәтгәрәй һәм Зиннәтгәрәй.

Бийморза, беренче углы Солтанай

Солтанайның бер углы Нәзир. Нәзир углы Туйкә. Туйкә углы Гыйбадулла, Гыйбадулла углы Гыйззәтулла, аның углы Габдулла.

Бийморза, икенче углы Сәфәргали, Сәфәргали углы Сәлим, Сәлим углы Габдерәззак. Аның бер углы Мөхәммәдколый. Мөхәммәдколыйның бер углы Мөхәммәдҗан.

Мөхәммәдшәриф Мөхәммәдҗан углы, аның улы Мөхәммәдвәли.

Мөхәммәдхәбиб Мөхәммәдҗан углы. Мөхәммәдхәбибтән туганнар: Әхмәдхафиз, Мөхәммәднәби, Мөхәммәдгәрәй.

Мөхәммәдхәниф Мөхәммәдҗан углы, аның углы Әхмәтвәли.

Мөхәммәдсадыйк Мөхәммәдҗан углы.

Мөхәммәдколыйның икенче углы Мөхәммәдзариф.

Мөхәммәдзарифның бер углы Җәләлетдин, икенчесе Һидийәтэтдин, өченчесе Мөхәммәдхафиз. Җәлалетдиннән

туган Минһаҗетдин, Кәшшафетдин, Һидийәтэтдиннән туган Шәрәфетдин.

Мөхәммәдхафизның баш углы Мөхәммәдгазый, икенче углы Миңнегалим, өченче углы Мөхәммәдшафыйк, дүртенче углы...

Бийморзаның өченче углының юлы

Бийморза, аның өченче углы Сөләйман, Сөләйман углы Йөзкәй, Йөзкәй углы Җәгъфәр. Җәгъфәр углы Хөсрәүшир.

Хөсрәүширнең бер углы Арслангали. Арслангали углы Гыймадетдин. Гыймадетдиннең бер углы Нуретдин. Нуретдин угыллары: Зыйатдин, Сәйәхетдин. Икенче углы Хәлфетдин. Хәлфетдин угыллары: Гайасетдин, Сираҗетдин, Хәсән, Галәветдин.

Гыймадетдин угыллары Ихсангали. Камалетдин, Җамалетдин, Сәлахетдин. Сәлахетдин углы Афзалетдин. Җамалетдин углы Таҗетдин.

Хөсрәүширнең икенче углы – Габделгаллэм. Габделгалләмнең бер углы Әмирхан, икенче углы Зиннәтулла, өченче углы Гафийәтулла. Гафийәтулла углы Хәбибулла. Зиннәтулланың угыллары Гатаулла, Фәтхулла.

Габдерәззакъның икенче углы Мөхәммәдәмин. Мөхәммәдәминнең бер углы Габделвәли. Габделвәли углы Галиулла, Галиулла углы Галимулла. Галимулла углы Заһидулла.

Мөхәммәдәминнең икенче углы Гали, янә өченче углы Габделгани. Гали угыллары Нәбиулла, Хәлилулла, Хәбибулла, Сафиулла. Нәбиулла углы Әхмәдвәли: Хәлилулла угыллары Шәрифулла, Гыйниятулла. Хәбиулла угыллары Шәфигулла, Карибулла, Миңнулла.

Сафиулла углы Шәмсулла.

Габдерәззакның өченче углы Ишәй. Ишәйнең бер углы Рәхимкол. Рәхимколның бер углы Асылхуҗа, икенче углы Гайфулла, өченче углы Насыйбулла.

Ишәйнең икенче углы – Мөхәммәдрәхим.

Бу Җәгъфәрнең икенче углы Габдесаттар. Габдесаттарның бер углы Галиулла. Галиулланың бер углы Шәһидулла. Шәһидулланың углы Карибулла, икенчесе Гыйниятулла, Гыйниятулла углы Миңнулал. Шәһидул-

ланың өченче углы Шәрифулла, Шәрифулла углы Хәбибулла. Шәһидулланың дүртенче углы Хөснулла.

Бу Йөзкәйнең икенче углы Әхийар. Әхийарның углы Балтукай. Балтукайның бер углы Шаһгәрәй, Шаһгәрәйнең бер углы Сәлимгәрәй, икенче углы Әхмәдхан. Әхмәдхан углы Сәгыйдҗан. Сәлимгәрәй углы ... гәрәй.

Балтукайның икенче углы Мөхәммәдгәрәй, анның улы Әхмәдвәли.

Бу Әхийарның икенче углы Сәфәргол. Сәфәргол углы Мөхәммәдгол. Мөхәммәдгол углы Зәйнелгабитдин.

Йөркәйнең икенче углы Фәйзулла. Фәйзулланың бер углы Ибраһим, икенче углы Исмәгыйль.

Исмәгыйльнең бер углы Хәбибулла, икенче углы Шәмсетдин.

Хәбибулланың бер углы Лотфулла, икенчесе Гыйниятулла, өченчесе Һидиятулла.

Лотфулладан туган Фәтхулла, Гыйззәтулла.

Шәмсетдин углы берсе Әһлиулла, икенчесе Габдулла.

... Йөркәй углы үзе Казанда булган... [Йөркәйнең] өченче углы Мөхәммәдгариф. Мөхәммәдгарифның баш углы Мөхәммәдхәниф. Мөхәммәдхәниф углы Минһаҗетдин. Икенче углы Мифтахетдин. Мифтахетдин углы Мөхәммәдфатих. Өченче углы Баһаветдин. Баһаветдин угыллары – Мөхәммәдхаррас, Сәхабетдин, Инсафетдин. Дүртенче углы Камалетдин, анның угыллары Галиулла, Габделгани.

Бишенче углы Җәлалетдин. Анның уллары Мәхмүдетдин, Әгъләметдин.

Галиулланың бер углы Вәлиулла. Вәлиулла угыллары Гарифулла, Әсәдулла, Кәрәмәтулла, дүртенче углы Гыйниятулла. Галиулланың бер углы Харрас Себер киткән.

Йөркәйнең дүртенче углы Рәйхан. Рәйханның баш углы Баһаветдин.

Баһаветдин угыллары – Гыймадетдин, Бәдретдин, Сәгъдетдин, Хәләфетдин.

Хәләфетдин углы Гайазетдин (шәҗәрә язылган кәгазьдә Гайазетдиннең ике углының исемнәре язылган урын ертылып, бозылган. – М.Ә.).

Рәйханның икенче углы Шәйехҗамал, аның углы Фәретдин. Фәретдиннең өч углы: Әф...; аның берсе Мөхәммәдсадыйк, икенчесе Әхмәдсадыйк.

Әхмәдсадыйкның ике углы – Мөхәммәдвәли. Мөхәммәдгата. Мөхәммәдвәлинең өч углы – Мөхәммәднәби, Шәйехразый, Нургали.

Шәйехҗамалның икенче углы Шәмсетдин, өченче углы Мирхәйдәр.

Мирхәйдәрнең беренче углы Асылгәрәй, икенче углы Җиһангәрәй, өченче углы Арслан, дүртенче углы Шаһгали, Шаһвәли, Шаһибәк.

Арсланнан туганнар – Мөхәммәдгәрәй, Бәхетгәрәй, Хаҗҗәмгәрәй, Әхмәдзәки, Ибраһим, Шаһихәйдәр һ.б.

Рәйханның өченче углы Мулла Әхтәм. Аннан туган – Шиһабетдин, Мөхетдин, Җамалетдин, Хөснетдин, Камалетдин, Мифтахетдин.

Җамалетдиннән туган берсе Гыймадетдин, икенче Кашшафетдин, өченче Әхмәдвәли. Әхмәдвәлинең бер углы Әхмәднәби, икенче Әхмәдгазый, өченче Әхмәдхәбир, туганнар Гыймадетдиннән берсе Мөхәммәдвәли, икенче Мөхәммәднәби, өченче Минһаҗетдин, дүртенче Галәветдин, бишенче Фәррахетдин, алтынчы Нургали, җиденче Арслан туган.

Мулла Әхтәмнең дүртенче улы Хөснетдин, беренче углы Хөснулла, икенчесе Нурулла.

Хөснулладан Сәмигулла, Шәһидулла туганнар.

Нурулла баласы читтә йөри.

Мулла Әхтәмнең бишенче углы Камалетдин. Камалетдиннән туган Фәттахетдин, икенче Мифтахетдин, өченче Гайнетдин, Фәттахетдиннән туган Минһаҗетдин, Мотыйгулла, Мифтахетдиннән туган Фәрсәхетдин, Галәветдин, Гайнетдиннән туган Хәйретдин.

Мулла Әхтәмнең алтынчы углы Мифтахетдин. Аның беренче углы Гыйлаҗетдин. Гыйлаҗетдиннән туган Баһаветдин.

Икенче углы Сираҗетдин, аннан туган Гыймадетдин белән Нуретдин.

Өченче углы Хисаметдин. Хисаметдиннән туган Фәррахетдин, Сәхаутдин.

Рәйханның дүртенче углы Сукыр Әхмәдҗан.

Чапай углы Хәмид, Хәмид углы Халид.

Халид углы Төхфәтулла.

Халид углы Гайнулал.

Төхфәтулла углы Кәлимулла, Төхфәтулла углы Гыйззәтулла.

Кәлимулла угыллары Хәбибулла, Заһидулла, Әһлиулла.

Гыйззәтулла углы Сәмигулла.

Хәбибулла углы Гыйззәтулла.

Заһидулла углы Әхмәдулла һәм Шакирҗан.

Сәмигулла угыллары Харрасетдин, Хафизетдин, Гарифулла, Афзалетдин.

Халид углы Гайнулладан туганнар – Габдулла, Хәлилулла.

Габдулладан туганнар – Шәйхулла, Лотфулла, Шәрифулла, Миңнулла.

Лотфулладан туганнар – Инсафетдин, Фәттахетдин.

Шәрифулладан туган Һибәтулла.

Миңнулладан туган Әсәдулла.

Хәлилулла бине Гайнулладан туганнар: Вәлиулла, Хәмидулла, Карибулла, Зәйнулла.

Халид углы Галиулладан туганнар – Сәлимгәрәй, Шафигулла.

Галиулла углы Сахибгәрәйдән туганнар – Һибәтулла, Гыйниятулла.

Гыйниятулладан туганнар: Миңнехан, Гыйндулла.

Галиулла углы Сәлимгәрәйҗән туганнар – Гыйнулла, Солтангәрәй, Нургали, Нурлыгәрәй.

Галиулла углы Шафигулладан туганнар: Габделхак, Габдулла, Сәмигулла.

Халид углы Гайфулладан туганнар: Әхмәдгәрәй, Нәгыймулла, Шәһидулла, Хәйрулла.

Әхмәдгәрәй углы Мөхәммәдгәрәйдән – Миңнегәрәй.

Әхмәдгәрәй углы Батыргәрәйдән туган – Гыйззәтгәрәй.

Гайфулла углы Әхмәдгәрәйдән – Дәүләтгәрәй.

Гайфулла углы Нигъмәтулладан туганнар Миңнулла белән Газизулла.

Гайфулла углы Шәһидулладан туганнар – Габидулла, Әхмәдулла.

Халид углы Хәйрулладан туганнар – Шәмсулла, Хөснулла, Габдулла, Исмәгыйль.

Чапай углы Хәмид; Хәмид углы Халид.

Хәмид углы Шәмсулла.

Хәмид углы Сәйфелмөлек, анын углы Шаһиәхмәд.

Янә Сәйфелмөлек углы Хаҗиәхмәд. Шәһиәхмәд углы – Шәмсиәхмәд. Хаҗиәхмәд угыллары – Алтынгәрәй, Әзәлгәрәй, Нуриәхмәд.

Уразбакый углы Шәгъбангали.

Шәгъбангали углы Галиәкбәр.

Галиәкбәр углы Әйүб.

Әйүб угыллары: Йуныс, Йосыф, Исхак, Йакъкуб, Мөхәммәдсафа, Исмәгыйль.

Мирас углы Кыдрач

Кыдрач углы Гыйльман

Гыйльман углы Каһарман, Ногман

Каһарман углы Миңнегәрәй, Шаһгәрәй, Мөхәммәдгәрәй, Сәйедгәрәй.

Ногман углы Миңнулла.

Мирас, икенче углы Илйас.

Иийас углы Гыйльфан.

Гыйльфан углы Ислам. Ислам углы Хәйретдин, Иматдин, Афзалетдин, Гыйльметдин.

Мирас углы Кадрәчнең икенче углы Мөхәммәдгәрәй, Мөхәммәдгәрәй углы Иийас, Иийас углы ...

Уразбакый углы Шәгъбәнгали, Шәгъбәнгали углы Галиәкбәр. Галиәкбәр углы Әййүб, Әййүб углы: Йуныс, Йосыф, Исхак, Йагъкуб. Мөхәммәдсафа, Исмәгыйль.

Гайсә углы Тимербай.

Тимербай углы Тимергали, Тимербай углы Корбангали, Тимербай углы Муллагол.

Тимергол углы Кәшшафетдин.

Корбанагли углы Фәррахетдин, Гайнктдин Гайнулла, Сәйфулла.

Муллагол углы Габделвәли.

Гайнетдин угыллары – Шәйхетдин, Имаметдин.
Саруш углы – икенчесе Бикбау.
Бикбау угыллары – Биктаһир, Әбелхайер, Билал.
Биктаһир угыллары Хәбибелнаҗар, Гыймадетдин.
Әбелхайер углы Габделнәфыйг.
Хәбибелнаҗар углы Әхмәдҗан.
Гыймадетдин угыллары – Гайтулла, Шәмсетдин, Гыйниятулла.
Габделнәфыйг угыллары – Габдеррәшид, Габдерәфыйк, Габделгазиз.
Габдерәшид угыллары – Мөхәммәдвәли, Габдулла.
Габдеррәфыйкның бер углы Габделкәбир, икенче углы Габделзаһир, өченче углы Габделсәгыйр, Габделбәдыйк.
Габделгазиздән углы Миңнегалим.
Билал бине Бикбау бине Саруш угыллары Җомагол, Шаһимәрдән.
Җомагыл углы Хәлиллулла.
Шаһимәрдән углы Әхмәдшаһ.
Хәлиллулла угыллары – Вәлиулла, Сәмигулла, Ибраһим.
Әхмәдшаһ угыллары – Миңнеәхмәд.

Саруш углы Сөендек.
Сөендек балалары – Рахманкол, Собханкол, Рәфыйк.
Рахманкол угыллары – Байазид, Гайнан, Шәрәфетдин.
Собханкол угыллары – Исламгол, Иманкол, Дәүләткол.
Рәфыйк угыллары – Гайнулла, Камалетдин.
Рәфыйк бине Сөендекнең өченче углы Хисаметдин.
Шәрәфетдин углы Гыйлаҗетдин.
Исламгол углы Әшрәфулла, Тимерхан.
Камалетдин угыллары Шәмсуар, Габделгани.
Хисаметдиннең угыллары – Миңнегол, Нәҗметдин, Хәлафетдин.
Хәлафетдин угыллары – Сәлахетдин, Фәррахетдинр.
Гайнулла углы Гайфулла. Гайфулла угыллары Хәмидулла, Миңнебай, Миңнешаһ, Миңнехан.

## Беренче текстка искәрмәләр

Шәйех Дирбеш шәҗәрәсен беренче тәртипләп өйрәнә башлаучы кеше Татарстан Республикасының Баулы төбәгендә яшәгән Хәмзә ага Вахитов булды, ул 1894 елда туган, Иске Баулы авылында яшәде. Без аның белән 1974 елның 15 июлендә очрашкан идек. Шул чакта ул үзенең нәсел һәм тирә-як авылларның тарихлары буенча белгән мәгълүматларны бик тәфсилләп өч сәгатьтән артыкка сузылган әңгәмәдә сөйләде. Хәмзә агай үзе дә шул Шәйех Дирбешнең Каһарман (Карман) дигән улыннан таралган нәсел вәкиле. Ул башта 1950/66 нчы елларда авыл һәм нәсел тарихын язгач, язылган мәгълүматын «Кызыл Татарстан» гәҗитенә җибәрә. Анда бик озак яткач, редакция аның язмаларын авыторның үзенә кайтаралар. Шуннан соң Хәмзә ага үзенең язганнарын Уфадагы Тарих, тел һәм әдәбият институтына җибәрә. Уфада озак кына яткач Хәмзә ага әсәренең язмышын сорап хат яза. Җавап итеп Хәмзә Камалетдин улы Вахитов язмаларын башкорт теленә әйләндереп, авторга җибәрәләр. Хәмзә аганың миңа бик аптырап: «Нигә минем язганнарымны борҗан башкортлары теленә аудардыгыз?» дип хат язган. Хәмзә агай мәгълүматларына караганда Шәйех Дирбеш баба һәм аның уллары башта Дим елгасы буена урнашкан булганнар. Хәзерге Баулы төбәге җирләре дә Шәйех Дирбеш һәм аның улларының җире була. Карман (Каһарман) бабасы бу җирләргә килеп Баулы авылына нигез салган булса кирәк.

Хәмзә Вахитов нәселеннән булган Наилә ханым Кашапова бабасының тарихын, заман таләпләренә туры китереп аны яңадан язып, аны матбугатка хәзерләгән. Аның язмаларына караганда тарих фәннәре кандидаты Таһир Кәримов нәсел тарихына кагылышлы архив документлары да тапкан. Ул документлар буенча XVIII гасыр урталарында Шәйех Дирбешнең балалары һәм оныклары Баулы елгасы буйларына килеп утырганнар[8]. Алар бу җирләрне үзләренә беркетү өчен Мәскәүгә барып аннан грамота алганнар. Монда бернинди дә башкорт җирләре булмаган, аларның атамалары да күренми. Шәйех Дирбешнең җир алганда бу якларда – Карман (Каһарман), Тукбирде, Ырыс, Байсубы,

[8] Кашапова Н. Стучится 350-летие Бавлов // Газета «Слава труду». – 2000. – 14 июля.

Туктамыш, Таубакты, Илбакты исемле балалары була. Документларда Карман, Шәйех Дирбеш һәм Урсай Тугаев кебек бабаларның Казан өязе, Җөри юлы Балтач авылы ясаклы татарлары икәнлеге күрсәтелә. Әлбәттә әлеге Балтач бүгенге Балтач район үзәген дә, шулай ук Әгерҗе төбәгендәге Балтачны да аңлатуы мөмкин.

Янә бер көчле документ Татарстанның хәзерге Менделеев районы Турай авылы зиратындагы кабер ташларындагы язмалар да сакланган. Ул зираттагы ике эпиграфик текст икесе дә Шәйех Дирбеш һәм Карабәк шәҗәрәләрендәге шәхесләрнең тормыш иткән вакыт һәм урыннарын күрсәтәләр. Мәсәлән беренче таштагы текст: «Тарих мең дә туксан бердә Байсубай баба аның углы Бийбулды, аның углы Мәсгут дөньядин үтте». Димәк 1091 елда үлгән Мәсгут Турайда яшәп үлгән, һәм хәзерге календарь исәбе белән 1680 елга туры килә. Шәйех Дирбеш шәҗәрәсенең Татарстан Республикасы Баулы төбәгенең Төмбарлы авылыннан табылган кулъязмасында Шәйех Дирбешнең Байсуба(й), Байсубиның Байбулды, Байбулды углы Байморза һ.б. күрсәтелә.

Башкириянең Туймазы төбәге Турай авылында табылган Шәйех Дирбеш шәҗәрәсе текстында Шәйех Дирбешнең җиденче углы итеп Максуд күрсәтелә.

Әлеге шәҗәрәнең Төмбарлыдан табылган икенче текстында Шәйех Дирбешнең сигезенче углы Байсубы, Байсубы углы Бийбулды, аның углы итеп Бийморза күрсәтелә.

Димәк әлеге тарихи шәҗәрәнең өч кулъязмасында да Шәйех Дирбешнең углы Байсубы, Байсубы углы Байбулды исемнәре урын ала. Шәҗәрәдә Шәйех Дирбешнең үз уллары саны сигез генә булып, алар арасында Мәсгут күренми.

Бу җәһәттән Турай авылында туып үскән тел галиме Риза Газизовтан аның яшь вакытларында авыл картларыннан хәтерләп калган сүзләре дә кыйммәтлеләр. Риза ага (1894–1981) ул мәгълүматларны без үтенеп сорагач үз кулы белән дә язып биргән иде. Хәзер аның тулы эчтәлеген бирәбез:

«Мин туган Турай авылы (Алабуга өязе-районы) картлары сөйләве буенча шушы Турайдан күчеп киткән крестьяннар Башкортстанда Бәләбәй өязендә авыл булып урнашып, авылга Турай исеме биргәннәр, имеш. Шул Башкортстан Тураенда да бер өлеш җирне Алабуга Турае крестьяннары җире дип таныганнар. Безнең авылның крестьяннары арасында шул җиргә хуҗа була алмабызмы икән дип уйлаучылар бар иде.

Бу истәлекне бирүче Алабуга Тураенда туган Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни сотрудник булып эшләгән Риза Салах улы Газизов.

10.XI.1978 ел».

Бүгенге Менделеев төбәгендәге Турай авылы зиратындагы икенче ташның да Шәйех Дирбеш шәҗәрәсенә катнашы бар. Ул таштагы «Тарих мең дә туксанда дирләр ирди, Турай углы Чувашай дөнйадин үтте ирсә, ушуб билгене мөселманнардин дога өмид өчүн хәлали Туйсолтан остабикә билге куйды». Бу таш куелган ел, хәзерге исәп белән 1679/1680 еллар арасына туры килә. Бу хәбәрдән Турай авылының салынуына Шәйех Дирбешнең улы сәбәпче булуына дәлил чыга. Турайның инде XVII гасыр башларында ук туганлыгын тәгаенләп була. Инде Чувашайның үлгән вакытта укымышлы абыз икәнлеге, аның хатыны Туйсолтанның остабикә саналуыннан аңларга мөмкин. Туйсолтан остабикәнең тарихи аңы югары булып, ул үзенең иренең хатирәсен мәңгеләштереп, эпитафик һәйкәл салдырып куйганыннан күренә. Кабер тирәләре ташлардан түбәсез дәрбә стеналары хасыйл булган. Ташта сакланган Чувашай шәхесе хәтере Шәйех Дирбеш шәҗәрә текстларында кертелми калуы, аның Турай авылында калып, күчеп китүчеләр хәтереннән югалуы күрсәткече булып торадыр. Шул ук вакытта Турай нәселе Татар Төмбарлысында дәвам иткән.

Баулыда яшәгән Хәмзә Вахитовның мәгълүматына караганда Шәйех Дирбешнең улы Каһарман (Карман) нәселе Дим буеннан килгән. Дим буе исә Меңнәр кабиләләре җире булып танылып урыс чыганакларында «Миң иле» диеп танылган.

Шәйех Дирбешнең нәселләре янына Ык буена XVII гасырның икенче яртысында хәзер Бәйрәкә, Туйкә, Балтач, Әгерҗе, Теләнче, Акбаш исемнәре белән мәгълүм булган авыллар нигезләп, Иж елгасы буе авылларыннан күчеп килүче татарлар күп булган. Беркадәр аларга ияреп удмуртлар да килеп утыра.

Шәйех Дирбеш чыгышы белән үзе Нугай Урдасы татарларының Меңнәр кабиләсе вәкиле булып, ул үзенең Иске ватаны булган Нугай Урдасындагы җиренә кайткан һәм Дим буенда яшәгән. Меңнәр кабиләсендә тиз арада ярашкан һәм аны бөтен башка Нугай Урдасыннан калган татарлар таныганнар. Юкка гына Шәйех Дирбешне Дим елгасы буйларын биләгән Мең кабиләсе башлыгы Канзәфәр (Казанфәр) би үзенең бишенче улы диеп танымаган. Без Шәйех Дирбешнең исемен Дим елгасының югары ягында Башкириянең Миякә

төбәгендәге шәҗәрәләрдә дә күрәбез. Димәк, бу шәхес Канзәфәр бинең кордаш-замандашы була. Шунысы кызыклы, Миякә төбәгендә Шәйех Дирбешнең биләгән җирләрен белсәләр дә, аның нәселе тармаклары аларга мәгълүм түгел.

Шәйех Дирбеш шәҗәрәләрендә бернинди башкорт ырулары белән бәйләнеш күрсәтелми. Бары тик Шәйех Дирбеш нәселеннән булган кешеләрнең Димнең югарыгы өлешендә биләгән җирләрендәге хуҗаларыннан Чурабан, Биктимер һәм Ырысның Елан башкортлар тарафыннан үтерелүләре генә искә алына.

Шәйех Дирбеш нәселләре Дим, Агыйдел, Зәй елгасы буйларында инде XIII–XIV гасырларда ук үзләренең бабаларыннан булган Балым солтанның Сакмар, Ык, Зәй елгалары буйларындагы борынгы үз биләмәләрендә[9] утырганнар. Бу җирләрдә шулай ук Балым бик нәселенең зур бер тармагы Хуҗасәйетовлар да, документлары белән хокукларын раслап җирләр биләгәннәр[10].

Хәтта ки Оренбург шәһәре янындагы борынгы Актүбә шәһәре урынындагы җирләргә Бичман солтаны, Карабәк, Балым солтан балалары 1744 елларда кайтып борынгы туфракларына утыралар[11]. Аларның асыл ватаннарына кайтып утырырлык егәрләре булган инде.

Шәйех Дирбеш нәселенең бу зур борынгы тарихлы шәҗәрәсе, аның берничә, бер-берсенә бәйсез рәвештә сакланып килгән һәм тутырылып барылган язма текстлары белән дә расланалар. Түбәндә без Башкириянең Туймазы төбәгендәге Иске Турай авылында 1974 елда яшәгән Миргасим ага Вәлиуллинда сакланган Шәйех Дирбеш шәҗәрәсенең текстын китерәбез.

Шәҗәрә тексты 72х44 см зурлыктагы аксыл саргайганрак, ләкин таза сакланышлы кәгазь табагына язылган. Текст коңгырт ясалма кара белән, татарның 1920 елда законлаштырылган гарәпчә язуның «яңа имлясы» кысаларында язылган. Язуы матур, ачык. Бу кулъязма тексты бүгенге көндә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе,

---

[9] Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 22 б.

[10] Әлеге хезмәттәге «Кара бик шәҗәрәсе» (III вариант): – 18 б.

[11] Искандаров Р., Искандаров А. Сеитов посад. Очерк по истории Оренбургской (Татарской) Каргалы. – Казань: Татар. книж. изд-во, 2005. – С. 14.

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсендә 99 коллекциядә 118 нче берәмлек булып саклана.

Шәҗәрә беренче мәртәбә «Татар шәҗәрәләре» җыентыгында 1995 елда яртылаш кыскартылып басылып чыккан иде. Шәҗәрә текстының борынгы бабалары Төмбарлы кулъязмасындагы кебек борынгы легендар мөселман шәхесләренә, суфыйларга барып бәйләнәләр. Без бу шәҗәрәне Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдъяр Мәхмүд хаҗи нәселенә ( –1549) бәйле дип саныйбыз.

Бу басмадагы текст беренче мәртәбә тулысынча басыла һәм аның өчен башка текстларга карата язылган искәрмәләр уртак дип карала ала.

*Марсель Әхмәтҗанов*

## Икенче кулъязма тексты

### *Шәйех Дирбеш шәҗәрәсенең Иске Турай тексты*

Төп бабаларыбыз Төркестанлыдыр. Сәлмән Фарсига[1] барып теркәләдер. Миркамал бине Булач бине Мирәләй бине Йармөхәммәд бине Хаҗи Әхмәд бине Әсә(н)димер шәйех бине Аста суфый бине Хаҗи Хәлим бине Баҗә Шәйех бине Әбелшәйех бине Сәгъраҗ бине Сасык бине Сабир бине Сафи бине Хаҗи Йулавыҗ бине Солтан бине Садыйрдыр (Сәлмән баба – Сәлмән Фариси дийә мәшһүрдер) димеш.

**I буын**
1. Миркамал

**II буын**
2. Нугай 1
3. Шәйех Дирбеш 1
Моның 12 углы бар
4. Таңатмыш 1
Бунының өч углы булмыштыр.

**III буын**
5. Турай 3
6. Туктамыш 3
7. Тукбирде 3
8. Тутай 3
9. Каһарман 3
10. Туйкә 3
11. Максуд 3
12. Ырыс 3
13. Байсуба 3
14. Солтан 3

15. ? 3
16. ? 3
17. Илбакты 4
18. Таубакты 4
19. Тәүкәй Киләй 4

**IV буын**
20. Мажтәк 5
21. Ардыка 6
22. Уразай 7
23. Имангол 9
24. Йанбулат 10
25. Миртамә 13
26. Алакай 19
27. Дусай 19
28. Биккенә 19

**V буын**
29. Сасык 20
30. Зайыт 21
31. Туктагыл 22
32. Киләй 23
33. Атнаш 24
34. Йәрмәк 25
35. Колай 26
36. Карай 26
37. Биктимер 27
38. Рысбәли 28
(Бүләкәндә)

**VI буын**
39. Туйгужа 29
40. Ишәй 30
41. Йулдаш 31
42. Мөхәммәдәле 32
43. Йулдаш 33
44. Бигәш 34
45. Ишембай 35
46. Мәлик 36
47. Балкан 37
(Төмбарлыда)[2]

**VII буын**
48. Тәмүш 39
49. Чәчәң 40
(Турайда торалар)[3]
50. Бикчәнтәй 42
51. Максуд 43
52. Йосыф 44
53. Йәрмәк 44
54. Йагъкуб 44
55. Госман 44
56. Йәһүдә 45
(Байлар авылында калганнар)[4]
57. Йаңабирде 46

**VII буын**
58. Шәнәй 48
(Төмбарлыда)
59. Максуд 50
(Баулыда)
60. Салих 51
(Төмбарлыда)
61. Айыт 52
62. Габдерәшит 53
63. Ишморза 53
64. Зайит 55
65. Арслан 55

**VIII буын**
66. Иштуган 61
67. Ишморат 61
68. Зөлмөхәммәд 63
69. Мәсгуд 64
70. Мәкәй 64
71. Мостай 64
72. Хәсән 65

73. Хөсәйен 65
74. Тимерпулат 65
75. Сафийан 65

**IX буын**
76. Габдел-налмады 66 (Баулыда торалар)
77. Фәлән 67
78. Бикмөхәммәд 68
79. Габдерәхим 69
80. Мәүлүд 70
81. Монасыйб 71
82. Ильйас 72
83. Шәмгун 73
84. Сирин 73
85. Йуныс 73
86. Йосыф 73
87. Йагъкуб 73
88. Әхмәдҗан 74
89. Шаһиәхмәд 74
90. Хаҗиморат 74
91. Хаҗиәхмәд 74
92. Габделкәбир 75

**X буын**
93. Тимерпулат 77 (Рәтамакта торалар)[5]
94. Габделлатыйф 79
95. Габделвәдүд 79
96. Габделхаликъ 79
97. Габделвахид 80
98. Фаварис 81
99. Мөстәкыйм 82
100. Шакирҗан 88
101. Вәйселкаран 88
102. Лотфырахман 88
103. Габделхак 88
104. Баймоарт 90
105. Хәбиб Солтан 90
106. Хәбибулла 90
107. Насыйбулла 90
108. Габделхәбир 92

**XI буын**
109. Гыйззәтулла 90

**XII буын**
110. Һидийәтулла 109

**XIII буын**
111. Харис 110
112. Әхмәдулла 110
113. Лотфулла 110

## *Иске Турай авылыннан башка бер кардәш нәсел шәҗәрәсе*

Тәмәк белән Бикмәт бертуганнар

**I буын**
1. Тәмәк
2. Бикмәт

**II буын**
3. Теләнче 1

**III буын**
4. Фәлән 3

**IV буын**
5. Бохар 4

**V буын**
6. Кәдһәрт 5
7. Телмәт 5

**VI буын**
8. Бардуһәрд 6
9. Ишкәй 7

**VII буын**
10. Нәзир 8

**VIII буын**
11. Сарум 10

**IX буын**
12. Кормәт 11
13. Туйкә 11

**X буын**
14. Иманай Пүгәч

**XI буын**
15. Биктимер 14
16. Чурапан 14
17. Уразай 14

Иманай, Чурапаннар белән башкорт булганнар. Алар утырган урын Ыкның башында, үзләре крипле йирендә.

### Икенче текстка искәрмәләр

[1] Сәлмән Фариси – Ислам динен Мөхәммәд пәйгамбәр заманында беренче булып кабул иткән фарсы (иранлы) кешесе. Мөхәммәд галәйһиссәлам бу кешенең нәселенә Ислам динендәге мөселманнарга сөннәт ясау хокукын канунлаштырып биргән.

[2] Төмбарлы – Татарстан Республика, Баулы төбәгенә карый торган Татар Төмбарлысы авылы.

[3] Турай – ТР, Менделеев төбәгендәге Турай авылы, яки Туймазы төбәгендәге Иске Турай авылы күздә тотыла булса кирәк.

[4] Байлар – ТР, Минзәлә төбәге Тау асты Байлар һәм Ютазы төбәге Байлар авылы дип гоман ителә.

[5] Рәтамак – Башкирия Йәрмәкәй төбәгендәге татар авылы.

*Марсель Әхмәтҗанов*

### Өченче кулъязма тексты

### *Шәйех Дирбеш шәҗәрәсе*

(*Татар Төмбарлысы авылында табылган икенче кулъязмасы буенча*)

Сәлмән Фарси нәселеннән бабаларның силсиләсе ушбудыр.

Угланлары, угыллары йир йөзендә торалар.

**I буын**
1. Шәйех Дирбеш
**II буын**
2. Илбакты 1
3. Таңатмыш 1
4. Теләнче 1
5. Биктимер 1
6. Чурапан 1
Чурапанны Йылан башкортлары үтергәннәр үзенең крипле йирендә
7. Байсубы 1
8. Ырыс 1
9. Буйкә 1
10. Караман 1
11. Тукбирде 1
12. Туктамыш 1
13. Турай 1

**III буын**
14. Таубакты 2
15. Тәүкилде 3
16. Анчы Үтмәк 4
17. Байбулды 7
18. Мәрдәш 8
19. Йанпулат 9
20. Имангыл 10
21. Уразай 11
22. Арык 12
23. Мачтәк 13

**IV буын**
24. Килйә 14
25. Апакай 15
26. Бикмәт 16
27. Байморза 17
28. Ходай 18
29. Әтнәш 19
30. Киләй 20
31. Туктагыл 21
32. Зайыт 22
33. Мамык 23

**V буын**
34. Урманай 24
35. Карай 25
36. Дусай 25
37. Бохар 26
38. Солтан 27
39. Синан 27
40. Арслан 28
41. Йулдаш 29
42. Ырыс 30
43. Мәмәдәле 30
44. Йулдаш 31
45. Ишәй 32
46. Туйгуҗа 33
47. Сафи 33
(Төмбарлыда)

**VI буын**
48. Мәлик 35
49. Йәркәй 38
50. Нәзир 38
51. Сәлим 39
52. Габдерәшит 40
53. Максуд 41
54. Урмәт 42
55. Бикчәнтәй 43
56. Чәчнәк 45
(Турайда)
57. Шәфи 46
(Төмбарлыда)

**VII буын**
58. Ишмәт 48

59. Иман 49
(Баулыда)
60. Туйкә 50
61. Габдерәззак 51
62. Салих 53
(Төмбарлыда)
63. Рәҗәб 54
64. Мәхсүт 55

**VIII буын**
65. Йәһүдә 58
66. Сәйет 63
67. Хәлил 64
(Баулыда)

**IX буын**
68. Йөзәй 66
(Төмбарлыда)

**Өченче текстка искәрмәләр**

Татарстан Республикасы Баулы төбәге Татар Төмбарлысы авылында табылган Шәйех Дирбеш шәҗәрәсенең икенче кулъязмасын 1946 елның 27 июлендә әлеге авылда яшәүче Әбүзәр Бәшаровтан (1872 елда туган) филология фәннәре кандидаты Фазыл Салих улы Фәсиев алган булган һәм аны үзендә саклаган. 1974 елда Фазыл ага аны өйрәнү һәм файдалану өчен шушы юлларның авторына бирде. Асыл текст гарәп графикасы тәгъликъ стилендә язылган.

Шәҗәрә тексты, зурлыгы 44,5х35,5 см зурлыктагы сыйфатсыз аксыл-саргылт төстәге кәгазьгә, имән каерысыннан ясалган коңгырт төстәге кара белән каллиграфиясе бик үк ялтырамаган рәвештә каурый каләмдә язылган, структурасы ягыннан башка татар шәҗәрәләренә ошамый. Анда Шәйех Дирбеш исеме уртага алынып, балаларының исемнәре аннан чыккан нурлар рәвешендә язылганнар.

Текст язылган кәгазь сигез кисәккә бөкләнеп, бөкләнгән урыннарыннан өзелеп чыгар хәлгә җиткәннәр. Ул басмага беренче мәртәбә тәкъдим ителә.

Шәҗәрә тексты бүгенге көндә Казанда Татарстан Фәннәр Академиясе, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты каршындагы кулъязмалар, фәнни һәм архив фондлары мирасханәсендә 99 коллекция, 1 тасвирдә, 193 сак. берәмлеге булып билгеләнгән.

*Марсель Әхмәтҗанов*

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз (*М.И.Әхмәтҗанов*) .......................................... 3
Миякә төбәгеннән Меңнәр кабиләсе шәҗәрәсе (*М.И.Әхмәтҗанов*) .......................................... 4
Канзәфәр би шәҗәрәсенең тарихи кыйммәте турында (*М.И.Әхмәтҗанов*) ............................ 7
СССР Фәннәр академиясенең Татарстан филиалына тапшырылмакта булган борынгы башкорт «би»ләрендән Канзәфәр би тугрындагы төзелгән шәҗәрәгә теркәлгән мәгълүмат түбәндәгечә (*Г.В.Вафин*) .................................................. 12
Искәрмәләр (*М.И.Әхмәтҗанов*) .......................................... 18

**Канзәфәр би шәҗәрәсе**

Канзәфәр би шәҗәрәсенә кереш сүз ................................ 19
№ 1 Дистан (Канзәфәр бинең беренче улы) ..................... 20
№ 2 Шәйех Хәсән (Канзәфәр бинең икенче улы) ............ 24
№ 3 Шәйех Дәрвиш (Канзәфәр бинең өченче улы) ......... 25
№ 4 Абүшахма (Канзәфәр бинең дүртенче улы) ............. 30

**Шәйех Дирбеш шәҗәрәләре**

*Беренче кульъязма тексты*

Шәйех Дирбеш шәҗәрәсенең Төмбарлы кульъязма тексты ............................................................. 35
Беренче текстка искәрмәләр (*М.И.Әхмәтҗанов*) ........... 45

*Икенче кульъязма тексты*

Шәйех Дирбеш шәҗәрәсенең Иске Турай тексты .......... 49
Иске Турай авылыннан башка бер кардәш нәсел шәҗәрәсе ................................................... 51
Икенче текстка искәрмәләр (*М.И.Әхмәтҗанов*) ............ 52

*Өченче кульъязма тексты*

Шәйех Дирбеш шәҗәрәсе (Татар Төмбарлысы авылында табылган икенче кульъязмасы буенча) .......... 52
Өченче текстка искәрмәләр (*М.И.Әхмәтҗанов*) ............. 54

***Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы***

**Турай, Миякә арасы – бар да меңнәр баласы**

*Научно-популярное издание*

Оригинал-макет – *Л.М.Зигангареева*
Усл. печ. л. 3,5   Тираж 300 экз.
Подписано в печать 28.02.2010 г.

Отпечатано в множительном центре
Института истории АН РТ
Казань, Кремль, подъезд 5
Тел. (843) 292–95–68, 292–18–09